ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# МӨХӘММӘДЬЯРНЫҢ «НУРЫ СОДУР» ПОЭМАСЫ

«МИЛЛИ КИТАП»

**ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ**

---

**МӨХӘММӘДЬЯРНЫҢ**

# «НУРЫ СОДУР»

**ПОЭМАСЫ**

ӘСӘРНЕҢ
ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНДӘ
САКЛАНА ТОРГАН КУЛЪЯЗМАЛАРЫ

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2009

УДК 902/904 + 821.512.145.0
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)
М 98

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм махсус мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

**Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы:** әсәрнең Татарстан
М 98 Милли китапханәсендә саклана торган кулъязмалары / төз.-авт.
Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2009. – 128 б. –
(«Татар археографиясе» сериясе; 4 нче китап).
ISBN 978-5-88473-052-6

Җыентыкта XVI гасыр татар шагыйре Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» поэмасының Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган ике кулъязма нөсхәсенең текстлары басылды. XVIII гасырда күчерелгән кулъязмаларның берсе 1023, ә икенчесе 1165 шигъри юлны тәшкил итә.

Поэманың 1997 елда нәшер ителгән тәнкыйди басмасы белән бу текстлар арасындагы аермалар һәм үзенчәлекләр тәгаенләп күрсәтелде.

ISBN 978-5-88473-052-6

УДК 902/904 + 821.512.145.0
ББК 63.2 + 83.3 (2Рос=Тат)

© Мәрданов Р.Ф., 2009
© «Милли китап» нәшрияты, 2009

## «БУ КИТАП ХАН ДОГАСЫ БЕРЛӘ ТӘМАМ...»

Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән бөек татар шагыйре Мөхәммәдьярның хәзерге әдәбият фәненә һәм бүгенге укучыларга зур күләмле ике әсәре – «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмалары мәгълүм. Шагыйрьнең үзе һәм әсәрләре турында галимнәр һәм әдипләр тарафыннан күп язылды, китаплар чыгарылды, поэмалары мәктәп һәм югары уку йортлары дәреслекләренә кертелде. Аның 1541 елда язган «Нуры содур» поэмасы – әдәбиятыбыз җәүһәрләренең иң кыйммәтлеләреннән.

Әдәбият галиме Шакир Абилов «Нуры содур» әсәренең тәнкыйди текстын әзерләп, 1997 елда аерым китап итеп бастырып чыгарган иде[1]. Анда «Нуры содур» поэмасы кулъязмаларының фәндә билгеле булган җиде нөсхәсе турында кыскача мәгълүмат бирелгән. Аларның өчесе Петербургтагы Көнчыгышны өйрәнү институты фондында, һәм берәр нөсхә күчермәләре Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендә, Башкортстан Милли китапханәсендә, Нәкый Исәнбәт архивында һәм Дамир Гарифуллин архивында саклануы әйтелгән[2].

Поэманың Ш.Абилов тарафыннан файдаланылмаган тагын ике кулъязмасы Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә саклана. Боларның берсе 1978 елда Әгерҗе районының Яңа Аккуҗа авылында табылган XVIII гасыр күчермәсе, икенчесе 1994 елда Әтнә районының Олы Мәңгәр авылында табылган XVII гасыр башы кулъязмасы. Икесен дә археограф галим Марсель Әхмәтҗанов тапкан. Бу кулъязмаларның фотокүчермә фрагментлары Мөхәммәдьярга багышлап нәшер

---

[1] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар, шигырь. – Казан: Татар. китап нәшр., 1997. – 336 б.

[2] Шунда ук. – Б. 32, 229.

ителгән нәфис альбомда басылып чыкты[3]. Шул рәвешчә, «Нуры содур» әсәре XX гасырның ахырына кадәр тугыз кулъязма күчермәдә билгеле булып килде. Аларның кыскача тасвирламасы Энҗе Кадыйрова хезмәтендә басылды[4].

Археография – гаҗәеп дөнья ул. «Нуры содур» поэмасының, бербер артлы диярлек, тагын ике күчермә нөсхәсе табылды. Алардан 1999 елда табылганы турында матбугатта хәбәр биргән идек[5]. XVIII гасырның беренче чирегендә күчерелгән ул ядкәр Кукмара районында сакланып калган. «Нуры содур»ның янә бер кулъязма күчермәсе 2004 елда Удмуртия Республикасының башкаласы Ижевск шәһәрендә табылды. Әсәрнең басма тәнкыйди тексты белән чагыштырганда соңгысының кызыклы үзенчәлекләре булуы хакында махсус мәкаләбез дә чыкты[6]. Мәкаләдә XVI гасыр әдибе Мөхәммәдьяр иҗат иткән «Нуры содур» поэмасының фәнгә билгеле күчермәләре барлыгы унбергә җитүе һәм шулардан алтысының Казандагы фәнни оешмаларда саклануы әйтелде. Соңгы табылган ике кулъязма Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116 т» һәм «2071 т» шифрлары белән саклана.

«Татар археографиясе» сериясенең бу чыгарылышында «Нуры содур» поэмасының Милли китапханәдә саклана торган ике кулъязма нөсхәсе текстлары басылды. Кулъязмаларның табылу урыннарына

---

[3] Мөхәммәдьяр һәм аның чоры = Мухаммедъяр и его время = Mohammediar and his Time / төз.-авт. Абилов Ш., Әхмәтҗанов М., Измайлов И. Альбом. – Казан: «Гасыр» нәшр., «Рухият» нәшр., 1997. *(Бит саннары куелмаган).*

Олы Мәңгәр авылында табылган кулъязманың факсимилесе «Болгар әдәбияты антологиясе» дигән сериядә 2007 елда нәшер ителгән китапта тулаем бирелгән (Мухаммедьяр. Произведения / пер. с булгарского тюрки. – М.: Булгар иле, 2007. – С. 367–411). Мирасханә җитәкчесе М.Әхмәтҗанов белдерүенчә, бу кулъязма факсимилесен Мәскәүдә бастырып чыгару өчен Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җитәкчелегеннән дә, шулай ук Мирасханә җитәкчесеннән дә бернинди рөхсәт бирелмәгән һәм аның «Болгар әдәбияты антологиясе»н бастыручылар карамагына ничек кергәнлеге билгесез.

[4] Кадирова Э. Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и мардан» и «Нур-и содур»: лексика. – Казань: РИЦ «Дом печати», 2001. – С. 11–16.

[5] Мәрданов Р. Кыйммәтле кулъязма // Китапханә хәбәрләре = Библиотечный вестник. – 2001. – № 1. – Б. 36; Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 128.

[6] Мәрданов Р. «Бу китап хан догасы берлә тәмам...» // Казан утлары. – 2005. – № 7. – Б. 164–166.

нисбәт итеп, алга таба алар турында «Уразай нөсхәсе» һәм «Ижевск нөсхәсе» дип шартлы атамалар белән язылачак.

Поэма тексты теркәлгән кулъязмаларның беренчесе (Уразай нөсхәсе) Кукмара районының төньягында урнашкан Уразай авылында яшәүче Имаметдин ага Ибраһимовларда сакланган. Китапханәдә эшләү белән беррәттән, Татар дәүләт гуманитар институты студентларына татар палеографиясе дәресләрен укытканда борынгы кулъязмаларның фәнни әһәмиятен тәфсилләп аңлатып килүем нәтиҗәсендә студентларның берсе – Гөлназ Гарипова 1999 елның 11 маенда Милли китапханәгә бер төргәк кулъязмалар китереп тапшырган иде. Кулъязма җыентыкларның берсендә «Нуры содур» әсәренең яңа күчермәсе килеп чыкты. 15,5х19,5 см зурлыктагы кулъязма шактый таушалган хәлдә. Кем, кайда һәм кайчан күчергәнлеге билгесез. Кәгазенең су билгеләре аның 1701–1710 елларда Һолландиядә эшләнгәнлеген күрсәтә. Димәк, поэманы XVIII йөзнең беренче чирегендә күчерелгән дип гөманларга мөмкин. Кулъязмада «Нуры содур» поэмасы текстының баш өлеше сакланмаган, төп өлеше һәм ахыры бар. Ул җыентыкның 12–28 кәгазьләрендә урнашкан. Анда барлыгы 508 бәйт (шигъри икеюллык) һәм җиде шигъри юл (яртышар бәйт) булып, поэма текстының барлыгы 1023 шигъри юлы сакланган.

Икенче кулъязманы (Ижевск нөсхәсе) бу юлларның авторы Ижевск шәһәрендә яшәүче Рәисә апа Дәүләтшинадан 2004 елның җәендә табып алды. Рәисә ханымның бабасы ягыннан туганнары, тулы бер династия рәвешендә, 1854 елдан алып 1930 елларга кадәр Иж шәһәрендә указлы имамнар булып торганнар. Аларның төп чыгышлары хәзерге Татарстанның Арча районындагы Оры авылыннан булган[7].

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы язылган, Ижевскида табылган әлеге кечкенә дәфтәрнең сакланышы уртача. Текстның үзендә кайсы елда һәм кем тарафыннан күчерелгәнлеге күрсәтелмәгән. Ләкин кәгазендәге су билгеләре буенча вакытын билгеләргә мөмкин. Филиграньнәрне өйрәнеп тикшергәч, поэма тексты язылган кәгазьнең 1748–1756 елларда эшләнгән булуы ачыкланды. Димәк, «Нуры содур»ның бу нөсхәсе якынча 1756–1770 еллар арасында теркәлгән дип чамалап була. Дәфтәр ике ягы да язулы, 11х17 см зурлыктагы 59 кәгазьдә. Текстның баш өлеше һәм ахыры сакланмаган. Бу кулъязма дәфтәрдә

[7] Бу хакта тулырак карагыз: Мәрданов Р. «Бу китап хан догасы берлә тәмам...» // Казан утлары. – 2005. – № 7. – Б. 164; Мәрданов Р. Иж шәһәрендәге татарлар тарихыннан. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2006. – 264 б.

«Нуры содур» әсәренең барлыгы 1165 юлы, ягъни 581 бәйт һәм яртышар бәйтле өч юл язылган.

Поэманың Ш.Абилов әзерләп чыгарган тәнкыйди тексты белән Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган шушы кулъязмаларны чагыштырганда эре һәм вак аермалар, күп кенә үзенчәлекләр барлыгы күренә. Мәсәлән, кайбер баб-бүлек башларында хәдисләрдән һәм Коръән сүрәләреннән шул бүлекнең эчтәлегенә туры килә торган аерым җөмләләр, хәзергечә әйткәндә, эпиграф рәвешендә бирелгән. Ижевск нөсхәсендә «Бишенче баб. Газа кылмак сүзләрен бәйан кылур» дип бүлек исеме язылганнан соң «Калә галәйһис-сәлам: рәҗәгъна мин җиһадил-ахирәти» дигән хәдис сүзләре бар. Шулай ук «Сабыр кылмак...» турындагы алтынчы баб башында Коръәннең «Али Гыймран» сүрәсенең 200 нче аятендәге «Йа әййуһа әл-ләзинә әмәну, әсбиру вә сабиру вә рабиту вә әттәку Аллаһә ләгалләкүм туфлихүнә» һәм тугрылык (туры сүзлелек) турындагы сигезенче баб исеме астында «Маидә» сүрәсенең 46 нчы сүрәсендәге «Калә Аллаһы Тәгалә: Вә мөсаддикан лима бәйнә йәдәйһи» дигән гыйбарәләр язылган. Поэманың Ижевск нөсхәсендәге алтынчы һәм сигезенче баб башларындагы кебек андый эпиграф сүзләр Уразай нөсхәсендә дә теркәлгән. Әлеге нөсхәдә исә, төп тексттан аермалы буларак, алар кызыл кара белән язылган. Алтынчы һәм сигезенче баб башларындагы шундый ук гыйбарәләр Олы Мәңгәрдән М.Әхмәтҗанов тапкан кулъязмада да бар икән[8]. Менә боларның берсе дә басма тәнкыйди текстта юк. 1997 елда чыккан китапта бары бер генә урында – гаделлек турындагы беренче баб исеме янында Коръәннең «Нәхел» сүрәсендәге 90 нчы аятенең «Иннә Аллаһә йәэмүрү бил-гадли вәл-ихсани» дигән өлеше эпиграф кебек бирелгән. Ул сүзләр Олы Мәңгәр кулъязмасында да бар[9]. Шулай итеп, «Нуры содур» поэмасының хәзерге вакытта фәндә билгеле кулъязмаларында ун бүлек-бабның дүртесендә шундый гыйбарәләр язылганлыгы ачыкланды. Поэманың бүлек башларында Коръән һәм хәдисләрдән өземтә бирү, әлбәттә, әдәби әсәрне бизи, аның мәгънәви асылын тирәнәйтә һәм тәэсирен көчәйтә. Бер төрле үк гыйбарәләрнең берничә кулъязмада очравы – аларның кулъязма күчергән кешеләр тарафыннан гына өстәлгән очраклылык түгеллегенә ишарә итә. Димәк, поэманың авторы Мөхәммәдьяр төп нөсхәдә үк шулай язган булган. Дөрес, һәр

[8] Мухаммедьяр. Произведения... – С. 382, 389.
[9] Шунда ук. – Б. 405.

бабның башында автор тарафыннан Коръән сүзләре һәм хәдисләр бирелгән булган дип әйтеп булмый. Чөнки Мөхәммәдьяр бүлек эчендә дә Коръән һәм хәдис мәгънәләрен татарчага тәрҗемә итеп, шәрехләп язган. Гомумән, Мөхәммәдьяр әсәрләренең Ислам дине тәгълиматына бәйлелеген галим Ш.Абилов игътибар үзәгенә куймаган. Совет чорында формалашкан атеист татар галименә, әлбәттә, Мөхәммәдьяр гуманизмының нигезендә Ислам гуманизмы ятуы турында, аңлап-белгән хәлдә дә, язарга читен булгандыр. Хакыйкатьне тәкъдир итеп язучылар да бар. Мәсәлән, әдәбият галиме Нәҗип Нәкъкаш «Нуры содур»-ның тоташтан Коръән һәм хәдисләрдәге фикерләр белән сугарылган булуы турында тәфсилләп язды[10].

Уразай һәм Ижевск нөсхәләренең басма тәнкыйди тексттан аермалы кайбер урыннарын күздән кичерик. Мәсәлән, Абилов басмасында 313 нче бәйтнең[11]:

Дөнйада олуғ кәрамәт ирүр ул,
Кем аның берлә табар җәннәткә йул,

– дигән бәйт Уразай нөсхәсендә:

Дөнйада олуғ һөнәрдер бу ғәза,
Кем аныңлә булур җәннәткә сәза,

– дип язылган.

Тәнкыйди текст басмасындагы 608 нче бәйтнең:

Йәнә сайәңезгә сығныб килгән кеши,
Ғадлеңез берлә йитәр барчә эши,

– юллары Ижевск нөсхәсендә:

Сайәңезгә бүкүн сәфир килгән кеши,
Ғәдлеңез берлә тәбар барча эши,

– рәвешендә бирелгән.

Басма китаптагы 679 бәйтнең:

Тәңренең һәйбәтендин нагәһан
Заһид мескин сусагаи ул заман,

– юлларындагы «тәңренең» сүзе Уразай нөсхәсендә «бу хисабның» дип бирелгән. Ә Ижевск нөсхәсендә бу шигъри юллар башкачарак, ягъни:

Бу һәйбәтдин исе киткәй ул заман
Заһид мескин сусагай нагәһан,

– дип теркәлгән.

---

[10] Нәкъкаш-Исмәгыйль Н. Мөхәммәдьяр иҗатында Коръән һәм хәдисләр // Мирас. – 1997. – № 8. – Б. 38–45.

[11] Бәйт саннары алга таба да шул китапта күрсәтелгән тәртип буенча биреләчәк.

Әсәрнең текстын баета торган мондый аермалар белән беррәттән, төгәллек-ачыклык кертә торган үзенчәлекләр дә очрый. Әйтик, моңарчы:

Кем мөбарәк Урдуға барсам үзем
Худның қотлуг йөзүн күрсә күзем,

– рәвешендә билгеле булган 730 нчы бәйт Уразай нөсхәсендә:

Кем мөбарәк Урдаға барса үзүм
Ханның қотлуг йөзен күрсә күзем,

– буларак, бөтенләй башка төсмер бирә. Ижевск нөсхәсендә дә бу бәйт шулай ук, үзгәрешсез диярлек, язылган. Менә моннан сүзнең Урдага барып, ханның йөзен күрү турында әйтелгәнлеге ачыклана. Ә Абилов файдаланган кулъязмаларда «хан» сүзе урынына «хут» яки «худ» дип бирелгән булган.

Соңгы табылган күчермә нөсхәләрдә поэманың моңарчы билгесез булган бәйтләре барлыгы да ачыкланды. Уразай нөсхәсендә яңа бәйтләрнең саны дүрт, ә Ижевск нөсхәсендә өчәү. Уразай нөсхәсендәге яңа бәйтнең беренчесе 301 һәм 302 нче бәйтләр арасында язылган:

Кем ғәзат берлә ачылур дин йули,
Дөнйада даим ғәза қыл, и вәли[12].

Яңа бәйтләрнең икенчесе ике кулъязма текстында да бер төрле үк, 319 һәм 320 бәйтләр арасында теркәлгән:

Кем ғаза малы ирүр әср-ү хәлаль
Алса кяфер малыны булмас вәбаль[13].

Бу бәйтнең бүтән кулъязма нөсхәләрдә төшеп калуына, күрәсең, аннан соң ук килә торган 320 нче бәйтнең дә нәкъ шундый ук «Кем ғәза...» сүзләре белән башлануы сәбәп булгандыр дип фаразларга мөмкин. Ягъни, янәшәдәге ике бәйтнең бер төрле сүзләрдән башланганлыгына карап, текстны күчергән кешеләр, ул бәйтне күчерелде дип исәпләп, төшереп калдырган булулары бик ихтимал. Моңа охшаш хәл алдарак язылган 301 һәм 302 нче бәйтләр арасындагы яңа бәйткә дә кагыла. Чөнки анда «Кем ғәза (ғәзат)» дигән сүзләр белән башлана торган өч бәйт рәттән килгән.

---

[12] Бу юллар Олы Мәңгәр текстында да шулай ук язылган (Мухаммедьяр. Произведения... – С. 392).

[13] Бу юллар да Олы Мәңгәр текстында бар (Мухаммедьяр. Произведения... – С. 391).

Тәнкыйди текстта булмаган яңа бәйтләрнең өченчесе ике кулъязмада да сүзе-сүзгә тәңгәл килеп, 604 һәм 605 нче бәйтләр арасында язылган:

Бу китаб хан доғасы берлә тәмам
Қилғанын бәйан қилур мөдам[14].

Дүртенче бәйт Уразай нөсхәсендә 639 һәм 640 нчы бәйтләр арасында, ә Ижевск нөсхәсендә 640 һәм 641 нче бәйтләр арасында бирелгән. Ул соңгысында:

Ғәфу қыл йазықларымны, и, ғәфур,
Йаратқаным, тағәтемне қыл қәбул!?

– дип язылган. Уразай нөсхәсендә «тағәтемне» сүзе «тағәт төнен» дип язылган һәм андагы рифмадаш сүзләре «ғәфу» белән «рәфү» рәвешендә[15].

«Нуры содур» поэмасының яңа бәйтләре ачыклану фәнни яктан, һичшиксез, зур әһәмияткә ия. Филология фәннәре докторы, галим Марсель Әхмәтҗанов «Нуры содур»ның 1978 елда үзе тапкан кулъязмасында да яңа строфалары булуы турында язган иде[16].

Болардан тыш, «Нуры содур» поэмасының тәнкыйди текстында төрлечә укылу ихтималы булган кайбер катлаулы сүзләрнең яңа кулъязмалар ярдәмендә дөрес укылышы ачыкланды. Мәсәлән, 631 нче бәйттәге:

И доғаларны ишеткән пак-ү тәк,
Хәзрәтеңә уш қылыб үзүм начақ,

– дип язылган «үзүм начақ» сүзтезмәсендәге икенче сүзне күчерүчеләре тарафыннан хәреф нокталары урыннарын алыштырып язуларына карап, кулъязма текстларда төрлечә укырга мөмкин. Ш.Абилов чыгарган китапта бирелгән искәрмәдә әлеге гыйбарәнең ике күчермәдә «йөзүм нәхак» дип, берсендә исә «йөзем нәҗакъ» дип язылганлыгы, ә дөресе «начакъ» (кәефсез) булуы әйтелгән[17]. Ә шушы җыентыкта басыла торган Уразай нөсхәсендә бу сүзтезмә «йүзүм нәҗак» дип, ягъни икен-

[14] Бу бәйт Олы Мәңгәр текстында да нәкъ шушындагыча язылган (Мухаммедьяр. Произведения... – С. 374).

[15] Бу юллар М.Әхмәтҗанов тапкан ике кулъязмада да нәкъ Уразай нөсхәсендәгечә теркәлгән (Мөхәммәдьяр һәм аның чоры... Альбом; Мухаммедьяр. Произведения... – С. 372).

[16] Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 71.

[17] Мөхәммәдьяр. Нуры содур: поэмалар... – Б. 237.

че сүзе نجاک рәвешендә язылган. Ижевск нөсхәсендә исә әлеге сүзтезмә хәрәкәләр белән «йүзүм бүхак» дип язылган. Мондагы بُخَاک (бүхак, бөхәк) сүзенең мәгънәсе – җиргә ору дигәнне, ягъни йөзне җиргә тигереп баш июне белдерә. Күчерүчеләр бу сүздәге хәрефләрнең нокталарын үзләре аңлаганча язып килгәннәр.

Тәнкыйди текстның 735 бәйтендәге «кот» сүзе бездәге ике кульязмада да «уау» өстендә тәшдид белән قوّة һәм قوّت рәвешендә, ягъни «куәт» дип язылган. Шул рәвешчә, басма китапта:

Урдуға бармақға һәм қот кәрәк,

– дигән шигъри юл:

Урдаға бармақға һәм қуәт кәрәк,

– дип укыла.

Әлбәттә, һәрбер яңа табылган кульязма истәлек уникаль, алар моңарчы билгеле булган әсәрнең текстына нинди дә булса яңалык өсти һәм төгәллек төсмере бирә. «Нуры содур»ның бу җыентыкта текстлары басыла торган нөсхәләре, һичшиксез, әһәмиятле археографик табышлар. «Нуры содур» поэмасының билгеле булган барлык унбер күчермәсе арасында текстларының тулылыгы ягыннан Ижевск нөсхәсе бишенче, ә Уразай нөсхәсе сигезенче урында тора.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең шушы күчермәләре һәм алардагы яңа бәйтләр, бүтән үзенчәлекләре булуы – бөек әдип иҗатын өйрәнүне дәвам итү белән бергә, киләчәктә гамәли тикшеренү-эзләнүләрне дә туктатмаска кирәклеген искәртә. Әлеге юнәлештә гыйльми китапханәләрдә, архив һәм музейларда тупланган биниһая зур кульязма мирасны җентекләп тикшерү уңай нәтиҗә бирергә мөмкин. Һәрхәлдә, Мөхәммәдьяр әсәрләренең тулы текстлары булмаса да, өзекләр рәвешендәге фрагментар күчермә нөсхәләре табылуы ихтимал.

«Нуры содур» поэмасының Милли китапханәдәге кульязмалары текстларын әзерләгәндә аларның киләчәктә Мөхәммәдьяр әсәрләренең тулыландырылган яңа басмаларына материал буларак кулланылачагы күздә тотылды. Ягъни, поэманың әлеге ике тексты Ш.Абилов тарафыннан әзерләнгән тәнкыйди текст белән чагыштырма рәвештә бирелде. Шуңа күрә Абилов китабындагы текстологик үзенчәлекләр (бәйтләрнең саннар белән билгеләнүе, транслитерация һәм пунктуация) «Нуры содур»ның бу басмасына нигез итеп алынды. Уразай һәм Ижевск нөсхәләрендәге сүзләр һәм хәрефләр язылышының Абилов

текстыннан аермалы урыннары (шул исәптән хаталы язылышлары да) курсив белән күрсәтелде. Болай итеп бирү – текстны укып файдаланганда, аерым бер дәрәҗәдә, читенлек тудыра. Әмма хезмәтебезнең төп максаты әдәбият һәм тел, тарих белгечләренә ярдәм йөзеннән эшләнүен истә тотарга кирәк.

Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 елгы басма тексты чагыштыру өчен бу җыентыкка өлге итеп алынганлыктан (ул китаптагы текстологик эшләнеш белән тулаем ризалашып җитмәсәк тә), алда әйтелгәнчә, сүзләрнең язылышын шул китаптагыча бирдек. Ризасызлыгыбыз шунда ки, тәнкыйди текстта безне канәгатьләндермәгән нәрсәләр шактый. Мәсәлән, гарәби кулъязмалардагы бер үк хәрефләр кириллицага төрлечә транслитерацияләнгән. Язылышта бер төрле үк булган برلا сүзе «берлә» дип тә, «берла» рәвешендә дә бирелгән. Бер үк сүзнең نكا кушымчасы төрлечә: *–еңә* дип яки *–енгә* буларак язылган. Текстларда еш очрый торган زمان (заман) һәм وفا (вафа) сүзләре 1997 елгы басманың текстологик эшләнеше таләбенчә «зәман» һәм «вәфа» дип бирелергә тиеш булса да, алар китапта, нигездә, «заман» һәм «вафа» буларак басылганнар. Шулай ук قيلسه (قيلسا) сүзе дә «қилса» диелергә тиеш иде. Бер үк сүз текстта төрлечә: «рәсүл Аллаһ» һәм «рәсүлел-лаһ» дип бирелүе белән дә килешмибез. Бу сүз «рәсүлуллаһ» диелсә, язылыш һәм әйтелеше ятышлырак булыр иде. «Нуры содур»ның 372 нче бәйтендәге шул ук мәгънәдәге «нәби Аллаһ» дип язылган сүз дә «нәбиуллаһ» булуы кирәк иде. Бәйт ахырларындагы рифмадаш сүзләрдә «ы» һәм «е» хәрефләренең «и» буларак язылышы да тотрыксыз. Әлбәттә, һәр очракта да «и»ләштерү мәгъкуль түгел. Ләкин шигъри аһәң ихтыяҗынча үзеннән-үзе таләп ителгән урында, мәсәлән, 210 нчы бәйттәге «аны» белән «мәне» сүзләре «ани» һәм «мәни» дип бирелсә, текстологик шартларга ярашлырак булыр иде.

Тәнкыйди басмада гарәп хәрефләрен кириллицага күчергәндә турыдан-туры транслитерацияләү уңышлы килеп чыккан дип булмый. Мәсәлән, борынгы кулъязмалардагы төрки-татар сүзләрендә ا (әлиф) хәрефе «а», «ә», «э» авазларын белдергән. Шунлыктан, поэманың кулъязма нөсхәләрендә сүз ахырында әлиф язылса да, аны һәр очракта да «а» буларак кына күчерү дөрес түгел. Әйтик, «берла» дип түгел,

ә «берлә» диелергә тиеш иде. Шулай ук, 289 бәйттәге «тәүәсина» сүзен дөрес рәвештә «тәүәсенә» дию, ә еш очрый торган «йәнаша» язылышын «йәнәшә» дип бирү зарур иде. Бу күренешкә капма-каршы булган, гарәп хәрефләре белән язылган һәм басылган текстлардагы сүз ахырында еш кына «а» авазын белдерү өчен ه һәм ـه хәрефләре язылу гадәте дә исәпкә алынмаган. Мәсәлән, тәнкыйди текстта «андә», «барчә», «ачғунчә», «тазә» рәвешендә бирелгән сүзләрне «анда», «барча», «ачғунча», «таза» дип язу уңышлырак булыр иде. Әгәр дә бу күренеш транслитерация кагыйдәләренә таянып эшләнгән дип каралса, ул очракта ک (кәф) хәрефенең ул китаптагы бер үк сүзләрдә, төрлечә итеп, «к» яисә «г» буларак бирелеше аңлашылмый. Гарәп хәрефләре белән бер үк язылыштагы «боерык» сүзе 566 бәйттә «бойруқ», ә 567 бәйттә никтер «буйруқ» дип язылган. Гарәп сүзләрендә «ләм» хәрефенең һәрвакытта да йомшак яңгырашын исәпкә алып, гарәби сүзләр ахырындагы «л» хәрефе артына нечкәлек билгесе куелганда укылыш дөрес булыр иде. Югыйсә, китаптан файдаланучылар «хал», «хәммал», «фозул», «җәмал», «зөлал», «вәбал» кебек сүзләрне бозып укырга мәҗбүр. 179 нчы бәйттәге «ла-җәрәм» дигән сүзне дә «л» авазының йомшак укылышын тәэмин итәрдәй берәр хәреф белән язу отышлырак булыр иде. Югыйсә, бу гыйбарә шул ук басмадагы 439 нчы бәйттә «ля җәрәм» дип, дөрес яңгырашка якын басылган бит.

1997 елда дөнья күргән китапта боларга охшаш кайбер текстологик җитешсезлекләр, кызганычка каршы, тагын да бар. Тик аларның һәммәсен тикшереп ачыклау безнең максат түгел. Ә монда санап үтелгәннәре Милли китапханә кульязмаларының текстларын шул басма белән чагыштыру рәвешендә тәкъдим иткәнлектән, мәҗбүри ризалашырга туры килүне дәлилләү өчен күрсәттек. Әгәр дә без бу җыентыкны үзебез дөрес дип тапкан транслитерациядә бастырсак, Мөхәммәдьярның төзәтелгән тулы җыентыкларын киләчәктә текстологик әзерләп бастыручылар һәм, гомумән, әдипнең иҗатын өйрәнүчеләр өчен өстәмә кыенлыклар тудырыр идек.

***

Бу җыентыкта «Нуры содур» поэмасының яңа табылган кульязмалары буенча әзерләнгән текстлардагы үзенчәлекләр, Ш.Абилов басмасындагы тәнкыйди текст белән чагыштырма сыйфатында, курсив белән аерып күрсәтелде. Бәйтләрнең тәртип санын белдергән номерлар,

Абиловтагыча бирелеп, өстәмә бәйтләр булган урыннарда бәйт саны янына «а» хәрефе өстәлеп күрсәтелде. Тәнкыйди текст белән чагыштырганда кайбер бәйтләрнең юллары алмашкан һәм аерым бәйтләрнең урыннары алга яисә арткарак күчкән очраклар бар[18]. Текстлардагы андый үзгәрешләр астөшермәләрдә искәртелде. Кульъязманың дефектлы булуы сәбәпле, поэма текстына өзеклек кергән өлешләр квадрат җәяләр эчендәге өчәр нокта белән, ә сүз яки сүзнең берәр кисәге (хәреф, иҗек) төшеп калган урыннар түгәрәк җәяләр эчендәге өч нокта белән белдерелде. Текстларга өзеклек кергән урыннарда кустод булган очракларда, аларга астөшермәдә искәрмә бирелде. Бәйт юллары эчендә урыннары үзгәргән сүзләр түгәрәк җәяләр эчендә курсив белән аерып күрсәтелде. Күчерүче тарафыннан сүз ахырларында яки бер үк төрле хәреф янәшәдә килгәнлектән, кабатлап язылмыйча, төшерелеп калдырылган хәрефләр квадрат җәяләр белән өстәлде. «Уау» хәрефе өстенә өч нокта куеп язылган сүзләрне 1997 елгы басма текстындагыча, «в» (мәсәлән, *дәвләт*) дип бирдек. «Нуры содур»ның Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган нөсхәләренең факсимилеләре бу җыентыкта бирелмәде. Чөнки Уразай нөсхәсенең кульъязмасы шактый дефектлы булганлыктан, аны бирү мөмкин түгел. Ә берсенең факсимилесен биреп, икенчесен бирмичә калдыру кулай күрелмәде.

[18] Поэма бәйтләренең урыннары төрле кульъязмаларда аермалы булуы турында Ш.Абилов, Э.Кадыйрова һәм башка галимнәр дә язган.

## Мөһим өстәмә

Бу урында бер кызыклы яңалыкны әйтергә тиешбез. «Нуры содур» поэмасының монда «Уразай нөсхәсе» исеме белән язылган тексты, алда әйтелгәнчә, кулъязма җыентыкның 12–28 кәгазьләрендә теркәлгән. Ә аның алдындагы 1–11 нче кәгазьләрдә тагын бер күләмле шигъри әсәр бар. Бусының башы һәм төп өлеше бар, тик ахыры сакланмаган.

Бу шигъри әсәр Ислам тарихында мәгълүм шәхес – Мансур әл-Хәллаҗга багышланган. Әсәрнең ахыры булмаганлыктан, аның кем әсәре икәнлеген тәгаен белеп булмый. Хәер, поэма текстының үзендә авторы күрсәтелмәгән булуы ихтимал. Чөнки дә иҗат иткән кешесенең исеме һәр әсәрдә язылмаган. (Шул сәбәптән булса кирәк, кайбер борынгы язма әдәби ядкәрләр китапларга кертелмичә һәм өйрәнелмичә йөртелә). Мәсьәләне ачыкламыйча торып, авторы турында фараз белдерергә иртәрәк булса да, әлеге поэманың теле һәм стиле, шигъри төзелеше Мөхәммәдьяр әсәрләренә бик якын булуын әйтергә тиешбез. Сүзебез дәлилсез булмасын өчен рифмадаш сүзләрнең кайберләрен санап үтик. Мәсәлән, әл-Хәллаҗ турындагы поэмада булган «сәлам = тәмам», «мәгәр = могтәбәр», «кеши = эши», «рәүван = заман», «хасс-ү гамь = тәмам» «кәрәк = кәрәк», «һаман = гайан» һ.б. рифмалар Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» белән «Нуры содур» әсәрләрендә еш очрый. Авторы кем булуына карамастан, тел-стиль җәһәтенә нигезләнеп, бу әсәрнең Мөхәммәдьярлар дәверендә иҗат ителгәнлеге аңлашыла.

Кулъязма җыентыкның XVIII гасырның беренче чирегенә нисбәтлелеген искә алганда, аңа кадәр төрки телле әдәбиятларда Мансур әл-Хәллаҗ шәхесенә багышланган күләмле шигъри әсәр булганлыгы безгә билгеле түгел. Төрек шагыйре Акмөхәммәднең «Кыйссател-Мансур әл-Хәллаҗ» исемле әсәре әдәбият тарихында мәгълүм, тик анысы бүтән. Һәрхәлдә, бу әдәби ядкәрнең текстын «Татар археографиясе» сериясенең киләсе чыгарылышларының берсендә бастыру өчен әзерләкне башладык. Авторлык мәсьәләсенә дә, бәлки, ачыклык керер.

# ПОЭМА
# ТЕКСТЛАРЫНЫҢ
# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА
# КҮЧЕРЕЛМӘСЕ

## *УРАЗАЙ НӨСХӘСЕ*

[...]
*12а кәгазь* Т*и*гүрәйен мән хәлифәгә аны,
Кем эчүб кәүсәр с*ы*вын, тынсун җаны.

Тәүәсенгә йөкләде с*ы*вны рәуан,
Тәүәгә *(...)* менде үзе ул зәман.

Кэчә-көндүз ойумады йул йөрүб,
Ашықыб тәүәсен*(...)* қатығ сөрүб*.

Чықты ул бадийәдин мескин ғәрәб,
Җәһ*әт* итеб қылды хәлифәни таләб.

Т*ак*и ул көн шаһ*(...)* ав*г*а атланыб,
Сәйд қылу йөрүр ирди имгәнеб.

[...]** иркән шаһны күрде нагәһан,
Кем йырақдин т*ө*з күр*(...)*де ул зәман.

[...]үб йетди ғәрәб,
Тәүәдин төшмәс иркән ул би-әдәб.

[...] дәмдә сәлам,
Сәв*е*нүр иркән сүзен әйде тәмам:

[...] кэлдем, хәлифә, бу зәман
М*о*на килтүрдем ғәҗаиб әрмаған.

[...] андақ әрмаған күр*г*әни йуқ,
Уш мона килтүрдем аны сәңа уқ.

---

* Бу бәйт белән аннан соңгысының урыннары алышкан.
** Кулъязманың кәгазе бу урында дефектлы.

Хәқ зийадә қылсун ғөмреңни, и шаһ,
Сәңа җәннәт сувын*(...)* килтүрдем, аһ.

Эчкел аны, *и* хәлифә, бил-лаһи уш,
Кем йөрәкең тазә булсун имди хуш.

Эчеб аның ләззәтени аңлағыл,
Мәңа инғам, күб н*и*мә бағышлағыл».

Ул с*ыв* хален күзә эчендә, ишет,
Эссе көнләр ирде, аңла, и йегет:

[...] исе йаман,
Тулды шаһ*ның* назик дәмағы ул заман.

[...] алды иленә,
Нагәһан тикүрде аны теленә;

*12б кәгазь* Күңли болғанды хәлифәнең рәуан,
Серрени қылды қәмуғлардин ниһан.

Әйде: «Җәннәт с*ыв*ы ирмеш, аңладым,
Бу ғәрәб айған сүзени *д*ыңладым.

Бире*ңез* мең алтун инғам үзенә,
Ғәйб қылмаңыз аның сез сүзенә.

Вәли үзе мундин уқ қайтсун рәуан,
Килмәсүн ул безем илә нагәһан».

Шаһ сүзе берлә қайтды теркенчә ул,
Тәүәсина мүнүб ул дәм тотды йул.

Сордылар *(...)*: «Ни с*ыв* ирди, падишаһ,
Кем ғәрәбни қылдыңыз мундин [...][*]

[*] Кулъязманың кәгазе бу урында дефектлы.

Падишаһ вәзиренгә әйде җәуаб.
Ул ойалыб бул[...]

«Бу Форат с*ыв*ын килүб к*и*чсә иде,
Сусаб [...]

Бәс ойалғай ирди *(…)* кылғаныдин, –
Ойалғай ирди сүзе йал[...]

Безни йитеб килгән кем ирсә ойалыб,
Үзе қылған эшедин хәйр[...]

Барса ирди, ни рәуа булғай иде,
Биргәнемезни әсиғ қылғай иде».

Чөнкә б*и*кләр шаһ сүзен тыңладылар,
*(…)* Ни кәрәм қылғанын аңладылар.

Җан вә дил берлә қылыб үкүш доға,
Падишаһға әйделәр йөз мең сәна.

## БИШЕНЧЕ БАБ
## **ғаза*т (…)* сүзләрен бәйан қылур**

И җәһан ғазиларының сәрүәри,
Сез ирүрсез [...]

Қылайым сезгә ғаза бабын бәйан,
Ғазилық ирүр [...]

*13а кәгазь* Ғазиларның васфы*(…)* хален аңлаңыз,
Уш гәзаүәт сүзләрени тыңлаңыз.

Кем ғаза қылмақ ирүр олуғ һөнәр,
Ғазилар булур җәһанда мөғтәбәр.

301a *Кем ғәзат берлә ачылур дин йули,*
*Дөнйада даим ғәза қыл, и вәли.*

Кем ғаза қылса җәһан ичрә мөдам,
Мәнзиле булур аның дарес-сәлам.

Дөнйа вә ғоқбаны ул хасил итәр,
Үз морадынға һәмишә ул йитәр.

Кем шөҗағәт қылса *һәр* дәм дөнйада,
Ул күрәр олуғ сәғадәт ғоқбада.

Бу хәдис ирүр, ишеткел, мөғтәбәр,
Кем бәһатур кешени тәңре сә*в*әр.

Нәчә кем бер йылан үлтүрсә ул,
Табар ул кеше бәһишткә күни йул.

Бәс намазда күрсәңез йылан-чайан,
Айамадин үлтүрүңез ул зәман.

Кем қылур хәлаиққа анлар җәфа,
Бу сәбәбдин аны әйд[е] Мостафа:

«Һәр кем ул қылса хәлаиқ*ғ*а зийан,
Мәғнә ичрә ир*де* ул ғәқрәб-чайан.

Кем зийанкяр кешени үлтүрсә, бел,
Йылан үлтүргән тик ирүр, – аңлағыл».

Дин дошман*(...)* даимән кяфир булур,
Ғазилар кяфир билә туқуш қылур.

Әнбийанең сыйфаты ирүр ғәза,
Кемгә кем қылса *(...)* тәңре ғәта;

Дөнйада олуғ *һөнәрдер бу ғәза*,
Кем аның*лә (…) булур* җәннәткә *сәза*.

[...] мөбарәк лотфыдин,
Кем рәсүл садиқ ирүр, фәхре дин.

*13б кәгазь* 315 Нәқел итәйем бер хәдис, мөғтәбәр,
Мәғнәсендин қылайым сезгә хәбәр.

Мәғнәсе бу ирүр, аңла, и йегет,
Төрк*(...)* теленчә әйтәйен, йахшы ишет.

Җан вә дил берлә ишет, қыл қәбул,
Кем мөбарәк ләфзыдин әйде рәсүл:

«Хәқ тәғалә қылды *б*әнем ризқым уш,
Бу сөнгүм күләткәсе *атында* хуш.

Йәғни кем ризқымны қылды ул уған,
Бу ғаза малындин, аңла, и җәуан.

*319а Кем ғәза малы ирүр әср-ү хәлаль,*
*Алса кяфер малыны булмас вәбаль.*

320 Кем ғәза ирүр рәсүлнең сифати,
Артар аның берлә ислам дәүләти.

*Һәр*кем эшләсә рәсүл эшен*(...)* мөдам,
Дин вә дөнйа эшләри булур тәмам*.

Бер хикайәт нәқел итәйем мөғтәбәр,
Кем Хәсән Басридин ирүр бу хәбәр.

Үзләри әйде кем күрдем бер йегет,
Ғазил*а*рдин ирди үзе, хуш ишет.

* Бу бәйттән соң тәнкыйди текстта булган «Хикайәт» (яки Ижевск нөсхәсендәге «әл-хикайәт») сүзе язылмаган.

Ул хикайәт қылды *ме*ӊ, тыӊлаӊыз,
Ғазилар әхуалени хуш аӊлаӊыз.

Кем тэӊиздә йөрүр ирдүк бер зәман,
Ғазилық қыл*у*б җәһанда нагәһан,

Йелләр эсиб қайнады бер көн тэӊиз,
Ғәрек булды тэӊиз ичрә кәмәмез.

Бер ағач өстүндә мәне йел ал*у*б,
Бер җәзирә ичрә чықарды салыб.

Ул җәзирә утлары зәғфәран иде,
Күрклүк*ен*дә җәннәти ризуан иде.

Ул җәзирә уртасында бер сарай,
Кем йырақдин нуры балқыр [...]

*14а кәгазь* Тамлари кир*беч(...)* – алтун, *бере* көмүш,
Дөрре-җәүһәр ул сарай ичрә үкүш.

Кердем ирсә ул сарайға мән рәуан,
Күрдем анда кем йатур бер қач җәуан.

Сач, сақаллары таранмыш, тазә уш,
Тунлари пакизә һәм үзләри хуш.

Ул сарай анлар билә пөр нур иде,
Үзләри анда йатыб ойур иде.

Күрүб анлар халени қур*у*қд*у*м, и йар,
Ташқару чықд*у*м, күрәрмән бер сәуар:

Ул ирүр хөсн-*ү* җәмалда би нәз*а*р,
Йыз*л*ығы ирүр аныӊ мөшк-ү гәнбәр.

Мәне күрүб әйде кем сүзлә сүзүң,
Кәмәсе сынған кеше ирүр үзүң.

Йул сорарсән, буйлә үқ барғыл рәуан,
Бер йегет күргәйсән анда нагәһан.

Сән йулуңни сорғыл ул дәм үзедин,
Ни бойурса, чықма аның сүзедин.

Йөрүдем, бардым, йулуқтум үзенгә,
Чүн нәзар қ*и*лдым мөбарәк йөзенгә,

Қылур ирди ул йегет анда намаз,
Ул намазын төкәтеб қылды нийаз.

Мәне күрүб ул дәм *эчрә*, хуш ишет:
«Кем ирүрсән кәмәсе сынған йегет.

Йул сорарсән, йөрүгел, буйлә рәуан,
Сәңа *у*тру килгәй *(бер пир)* бу зәман.

Сән сәлам қ*и*лыб аңа, сорғыл хәбәр,
Кем үзе ирүр *(...)* җәһанда рәһбәр».

Йөрүдем, *и*лгәрү күрдүм үзени,
Кем намаз әйтеб сөртәр йөзени.

[...]рү аңа қылдым сәлам,
*(...)* Сурәт *вә* мәғнәдә ирди ул тәмам.

*14б кәгазь* Мәңа әйде: «К*и*мәсе сынған кеше,
Тотмағыл күңлүндә йулың тәшвише.

Йул сорарсән, әйтәйем, орғыл қәдәм,
Раст йөрүгел буйлә уқ имди бу дәм».

Бу йегет әйде кем: «И пир*е* лятиф,
Барчә мәғнә ичрә ирүрсән шәриф.

Теләкем улдур, мәңа қылсаң бәйан,
Мончә төрлүк күргәнем эшни ғәйан.

Күб ғәҗаиб төрлүк эшләр күрдем уш,
Мәңа андин қыл хәбәр, и *(...)* пир хуш».

Пир әйде: «Әйтәйем барчәсын сәңа,
Бу дәм ичрә хуш қолақ, тотғыл мәңа:

Ул сарай кем күрдүң аны ул зәман,
Ул шәһидләр қәсры ирүр, и җәуан.

Анда йатқан кешеләр ирүр шәһид,
Мең йыл ирүр йатқаны анлар, ишет.

Күргәнең атл*и*ғ кешедүр – Җәбраил,
Көн дә ике қурла килүр, аңлағыл.

Ул йегет кем күрдүң ул Илйас ирүр,
Кем үзе даим зийарәт*қ*а килүр.

Мәне сурсаң, Хөзер ирүрмән, и йегет,
Уш сәңа қылдым хикайәт, хуш ишет.

Бер доға үгрәтәйем, йегет, сәңа,
Аны уқуб кер бу сағәт йулыңа.

Йомуб ачғунчә күз*е*ңни сән рәуан,
Теләгән йиреңә тиггел бу зәман».

Ул доғаны мән уқудым ирсә уш,
Күз йомуб ачғунчә килдем *ив*гә хуш.

## АЛТ*Ы*НЧЫ БАБ
## сабыр қылмақ сүзләрен бәйан қылур

*«Йа, әййуһа әлләзинә әмәну, әсбиру вә сабиру вә рабиту [вә эттәқу Аллаһә] ләғалләкүм түфлихүнә*[*]*»*

*15а кәгазь* Уш күңүл эчендин *уқыб (...)* сәбақ, –
Сүзләри берлә бизәйем уш вәрәқ.

Җан вә дил берлә ишетеңез қәмуғ,
Шәрех итәйем аны, и кечек, олуғ.

Сабыр бабын қылайым сезгә бәйан,
Сабыр итеңез барчә эшдә һәр зәман.

Сабыр қылмақ иргә ирүр хуш һөнәр,
Сабыр қылған кешени тәңре үгәр.

Тәңренең рәхмәтләре даим, ишет,
Сабыр қылғаннарға булур, и йегет.

Барчә тағәт башы, аңла, сабыр ирүр,
Сабыр қылған иргә Хәқ дәүләт бирүр.

Дустлық ичрә сабыр қылсаң, и ғәзиз,
Қәтрә иркән булур ул дуст *төшеңез*.

Дошман үзә сабыр қылсаң *(...)* үкүш,
Ғақибәт аны йеңәрсән, аңла хуш[**].

Сабыр берлә барчә эш хасил булур,
Сабыр қылған даимән ғақил булур.

---

[*] Коръәннең «Али Гыймран» сүрәсенең 200 нче аятеннән алынган бу гыйбарәдәге квадрат җәяләр эчендә бирелгән сүзләр кульязмада юк.
[**] Бу бәйт белән аннан соңгысының урыннары алышкан.

*С*абир атлы*(...)* бер сәхабә, и йегет,
Сабыр ирди Хәқ йулунда, хуш ишет.

Үзләри қылды риуайәт, тыңлаңыз,
Мостафаның хәзрәте*н*дин аңлаңыз:

«Сабыр берлә хасил итәр ир морад,
Сабыр*(...)*лә қайғу булур барчә шад».

Ул нәби*уллаһ* Йағқуб, хәзин,
*Арзулаб* күрмәде *(чөн)* Йусыф йөзен,

Дәрд-*ү* ф*и*рқәт ичрә даим руз-у шәб,
Сабыр қыл*ы*б қылды Йусыфны таләб,

Ғақибәт табты аны ғиззәт билә,
Йөзени күрде аның дәүләт билә.

[...] ирсә Йағқуб – бер зәман
Булды Йусыф васлы берлә шад*ы*ман.

*15б кәгазь* Бер кем ирсә Мостафаны күрде ул,
Бәс имандин үзләренә сорди ул:

«Кем ни булур иман, айғыл, *(...)* рәсүл,
Ишетеб аны қылайым уш қәбул».

Мостафа бойурды аңа ул зәман,
Кем айайын, тыңла имди, и җәуан:

«Сабыр қылмақ ирүр иман, бел йәқин,
Хәқ йулында сабыр қыл, и әһле дин.

Қайу кеше сабыр қылса ул мөдам,
Ул кешенең булур иманы тәмам.

Сабыр қылмақ ирүр әүвәле ачиғ,
Һич нәмә йуқ дөнйада андин қатиғ.

Соңы балдин сөчүк ирүр, и җәуан,
Сабыр берлә күчай эш булур асан.

Сабыр қылған кешеләрни хасс-у ғам –
Барчә ғаләм хәлқы сәвәрләр тәмам.

Барчә *и*шдә сабыр қ*и*лғыл, и ғәзиз,
Сабыр сүзен аңла, и ғәқлы тәмиз.

## ХИКАЙӘТ

Нәзым итәйем бер хикайәт имди уш,
Ишетеңез мәҗлес әһле барчә хуш.

Кем Хорасан мөлке ичрә бер мәлик
Бар*ча* ирди, тыңла, и гәнҗ б*елең*.

Аты ирди *Б*усәғид, аңла аны,
Хикәм берлә тотмыш ирди дөнйаны.

Бер вәзире бар иде аның мәгәр,
Ғилм-ү хикмәт ичрә ирди мөғтәбәр.

Аты ирде *Бүл*-Мөзаффәр үзенең,
Кем мотиғы ирди ғалим сүзенең.

Падишаһ бер көн мәгәр үзе билә
Мәшғул ирди мәшүәрәт сүзе билә.

Итүке эчендә аның бер чайан
Тигәр ирди ул вәзир[...]

*16а кәгазь* Нәчә тигәр ирди ғәқрәб үзени,
Кэсмәз ирди шаһ*(…)* берлә сүзени.

Сүзләйү торған сүзен йаңылмады,
Хале аның һич тәғйир булмады.

Шаһ берлә сүзләрен сүзлә*де* хуш,
Сабыр қылыб зәхмә*те гизләде х*уш.

Шаһ қатындин тарқады бикләр қәмуғ,
*Ив*гә барды барчәси – кечек, олуғ.

Ул вәзир һәм барды *ив*гә ул зәман,
Ашықыб чықарды итүкен рәуан.

Чүн чықарды итүкен *ив*гә барыб,
Салды ғәқрәбни итүкдин чықарыб.

Падишаһға тигди ул дәм*дә (…)* хәбәр,
Таңлады ул вәзир эшенә мәгәр.

Өндәб әйде аңа: «Кем сән, и вәзир,
Ғәқел эчендә ирдүң *(…)* би нәзыйр.

Сән*(…)* ғәқрәб ул зәман т*и*ггәндә уқ,
Ни сәбәбдин чық*(...)*мадың *сән* анда уқ.

Дәфеғ қылмадың сән аның шәррен*(...)*,
Нуш қылдың *(...)* анда торуб зәһрени».

Ул вәзир әйде: «Кем, и шаһи җәһан,
Хәзрәтеңездә қылайым уш бәйан.

Сез мәңа мончә үкүш ихсан қылыб,
Үзүңүзгә *ни* сез мәхрәм белеб,



*«Нуры содур» поэмасының Уразай нөсхәсе. 16б кәгазь.*

Мәшүәрәткә мәне лайық күрдүң*ү*з,
Серреңез сүзен*(...)* мәңа белдүрдүң*ү*з.

Мәңа сез сүз әйтүр иркән ул зәман,
Тигте ирсә мәне ғәқрәб *ул* нагәһан,

Әйтә торған сүзеңез тыңламайын,
Ул бойурған эшеңез аңламайын,

[...] ташқару, *(...)* шаһе җәһан,
Булғай ирди әсиғым барча зийан.

*16б кәгазь* Ул ғәқрәб тиггәнигә түзмәдин,
Сезгә *мән* сабрым барын күргүзмәд*ем*,

Бер тиггән зәхм*ен*гә ул дәм бақыб,
Китсәм ирди хәзрәтеңездин чықыб,

Бәс сезнең дошманларыңыз хәрбенгә,
Йағиларыңыз қылычы зарбенгә

Мән нэчүк түзгәй и*(...)*дем, шаһе җәһан,
Қол сезнең мән, сез белүрсез *ли*л-әман».

Ул вәзир*(...)* сүзен солтан тыңлады,
Ғақиланә сүзләгәнен аңлады.

Шаһ*қ*а хуш килде аның бу сүзләри,
Қылды инғам вәзиренгә үзләри.

Чөн аның ғақиллығыны белде ул,
Мәмләкәтни аңа тәслим қ*и*лды ул.

Қайу кеше сабырлық булса үзе,
Ғақибәт табар морад бәс ул үзе.

## ЙЭТЕНЧЕ БАБ
**вәфа сүзләрен бәйан қылур**

И вәфа иқлим*(...)*нең шаһи йәқин,
Кем вәфаңыз нуры*(...)*дин руйи зәмин

Кичә-көндүз даимән рушән ирүр,
Йаз вә қыш ғаләм қәму*(...) килмеш* ирүр.

Уш вәфа бабыны тәхрир итәйем,
Сүзләрен*(...)* сезгә тәқрир итәйем.

Бу вәфа ирүр, ишет, нуры җәһан,
Кем аның берлә *булур* бу *ир мөгтәбәр*.

Бел вәфа ирүр җәһан ичрә һөнәр,
Кем вәфа берлә булур ир мөғтәбәр.

Моғтәбәр булмақ теләсә һәр кеше,
Даимән булсун вәфа қылмақ эше.

Қай*у* ир кем [...]
Ул [...]

*17а кәгазь* Бу вәфа, аңла кем, өч төрлүк *булу*р,
Кем вәфа қылса, сәламәт, хуш йөрүр.

И бәр*а*дәр, бер*(...)*е ирүр ғәһд эше,
Ғәһд қылса Хәқ йулында һәр кеше,

Важиб ирүр қылмақ *(ул)* ғәһди вәфа,
Қылмаса күрәр қийамәтдә җәфа.

Бәс икенчесен айайын, тыңла уш,
Вәғд[ә] қылса кешегә бер нәмә хуш,

Ул кеше күңлүн сафа қылмақ кәрәк,
Вәғдәсенгә хуш вәфа қылмақ кәрәк.

Вәғдәгә қылған вәфа булур кәрим,
Бу – хәдис мәғнәсе ирүр, и хәким.

Бел, өченчесен айайын, тыңлаңыз,
Мәғнәсен*е* шәрех итәйем, аңлаңыз.

Падишаһ вә бик, вәзир берлә қәмуғ,
Бер кем ирсә шарт қылса *(...)*, и олуғ,

Кем м*и*не сез асрасаңыз хуш күрүб,
М*и*н тәқи үлгүнчә та*б*уғда т*өрүт*,

Көчүм йитәрчә сезгә хезмәт қылғаймән,
Сезгә даим мән һәуадар булғаймән.

Бу йусунлуғ вәғдәгә қ*и*лса вәфа,
Хезмәтендин китмәсә күрүб җәфа,

Ул кеше булур вәфадар, и йегет,
Уш вәфа әһле сүзен йахшы ишет.

Әйтәйем әсхабы кәһәфнең қиссәсен,
Кем китәрүр ул күңүлнең *(...)*сәсен.

Бер күчүк қылды чөн анларға вәфа,
Дөнйа вә ғоқбада табты ул сафа.

Чөн кем анларға ийәрде ул зәман,
[...]

[...] арыб йатмады.

*17б кәгазь* Қылды ирсә ул вәфаны ихтийар,
Ля җәрәм булды вәлиләр берлә йар.

Бәс вәфа берлә сафа хасил булур,
Ул сафа берлә сәғадәт табылур.

Ул сафа сөффәсенең шаһы тәмам,
Ул вәфа қөббәсенең маһы мөд*а*м,

Дин вә дөнйа, йер, күкнең мөфәххәри,
Өнс-ү җан вә *тин* пәйғамбәри:

Нәқел итәйем бер хәдис үзендин уш,
Төрк теленчә мәғнәсен аңла хуш.

Кем кәрим ул ирүр, аңла, и җауан,
Вәғдәсенгә ул вафа қылса рәуан,

Вәғдәгә қылмақ вафа ирүр кәрәм,
Бәс вәфа қыл вәғдәгә һәр дәмбәдәм.

## *(...)*ХИКАЙӘТ

Ишетеңез бер хикайәт имди уш,
Бер мәхәллә бар ирди Бәғдадда хуш.

Ул мәхәллә әһле ирди барчә бай,
Күрмәз ирди анда кеше һич гәдай.

Һәр ки мөфлис булса ирди нагәһан,
Малларындин бирүр ирдиләр рәуан.

Қәйра хуҗа қылур ирдиләр ани,
Булур ирди ул борунғы тик ғәни.

Ул мәхәллә ичрә бер хуҗа мәгәр
Булды мөфлис нагәһан, ишет хәбәр.

Аты ирди Хамид Қоттан, *(...)* йегет,
Булды ирсә мөфлис үзе, хуш ишет.

Ул мәхәллә қәуме йыйғылыб қәмуғ,
Барды Шәмғун ә*в*енгә кечек-олуғ.

[...]
Малы күб ирди, [...]

Йыйғылыб [...]
Хамид [...]

*18а кәгазь*
Әйделәр кем тәңрелық өчен аңа
Буручқа биргел *биш* мең ақча, без сәңа.

Аның өч*ү*н барчәмыз йөк булалым,
Вәғдәси йетсә, әда без қылалым.

Шәмғун анлардин ойалыб ул зәман,
Бирәйем тиб вәғдә қылды нагәһан.

Күңле ичрә Шәмғун әйде *(...)* бу көн
Вәғдә қылдым, бирәйем тәңре өч*ү*н.

Ул кичә йат*д*ы, ойуды, нагәһан
Йоқлайурда төшүндә Фәхр*е* җәһан

Әйде: «Аның хаҗәтен қылдуң рәуа,
Без тәқи уш дәрденгә қылдуқ дәуа».

Сорды Шәмғун: «Кем айа нуры җәһан,
Атыңызны әйтеңез мәңа рәуан.

Сезгә бер дәм, ин[...]*г*дә булалым,
Н*и* бойурсаңыз – мән аны қылалым.

Йөзүңез нурын күрүб тынды җаным,
Сездин уқ ирүр – белүрмән-дәрманым».

Әйде: «Кем сорсаңыз мәне, Шәмғун, бу дәм
Сидық берлә дин йулына қуй қәдәм.

Хәқ рәсүле мән, Мөхәммәд – атым уш,
Ғәрз итәйем сәңа иман имди хуш.

«Әшһәде әл ля иляһ» тиб рәуан
Ай*қ*ыл: «илля-л-ляһ» сүзени, и җәуан».

Шәмғун әйде: «Хәқ рәсүле Мостафа,
Күңлүм ичрә тулды уш с*е*здин сафа.

Тәңре [...]
Қылдым ислам динени бу дәм қәбул».

[...]*

*18б кәгазь*

## СӘКЕЗЕНЧЕ БАБ
## сидық сүзләрен бәйан қылур

*Қалә Аллаһы тәгалә: «Вә мусаддиқән лима бәйнә йәдәйһи»*

И җәһан ғашиқларының садиқы,
И зәман садиқларының ғашиқы.

Ғишық берлә сидық сүзен*е* тыңлаңыз,
Тәқрир итәйе*н* аны – хуш аңлаңыз.

* Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, бу урында текстка өзеклек кергән. Анда поэма текстындагы 469 һәм 470 нче бәйтләр язылган булган.




*«Нуры содур» поэмасының Уразай нөсхәсе. 18б кәгазь.*

Сидық бабын қылайым сезгә бәйан,
Ул бәйан берлә аны күрең гәйан.

Төрк*(...)* теленчә сидық мәғнәсен белең –
Күнилек берлә һәмишә эш қылың.

[...][*]

Қайу кеше теләсә дә*в*ләт тәмам,
Күни булсун сүзләре аның мөдам.

Күнүлүк берлә табар дә*в*ләт қәмуғ,
Күни сүз берлә булур кечек олуғ[**].

Кем олуғл*уг* теләсә даим үзе,
Барчә берлә хуш, күни булсун сүзе.

Күниләр[р]ни барчә ил-у*(...)*с сәү*в*әр,
Күни сүзләгән кешени Хәқ үгәр.

Адәм уғлының вөҗүде ичрә бел:
Бер тылсым бу әл-ғәҗәб ирүр бу тел.

Кем җәһан эчендә, и дин олуғы,
Гәнҗ, дәүләт, рәнҗ *вә* михнәт-қамуғы

Ул тылсым ачқуч*(...)* берлә ачылур,
Нә ки телдин чықты – ул бағыңа килүр.

---

[*] Тәнкыйди текстта һәм Ижевск нөсхәсендә бу урында булган 475 нче бәйт монда язылмаган.

[**] Ш.Абилов басмасында «кечек-олуг» дип ике сүз арасына сызыкча ялгыш куелган. Чөнки монда автор «кечек» кешенең «күни сүз берлә» олуг булуын күздә тоткан дип уйлыйбыз.

Тел күни булса, күнүлүр *ил*, азақ,
Күни [...][*]

*19а кәгазь* Ул – нәбүвәт мәғдәненең җәүһәри,
Ул – рисаләт тэңизенең гәүһәри.

Сахибе миғраҗ садре*(...)* *әт*бийа,
Фәхр*е* ғаләм Хәқ рәсүле Мостафа.

Ул мөбарәк ләфзыдин *имди* үзе,
Ишетеңез бу ирүр айған сүзе. –

Нәзым берлә әйтәйем сезгә аны,
Ғәиб қылмаңыз бу сүздә сез мәне.

Адәм уғлы уйғаныб торса рәуан
Сабах йатқан йерендин нагәһан,

Телгә әйтүр бу қәмуғ әндамләри,
Хал теле берлә ишеткел һәрбери:

Кем ирүрсән безгә, и тел, сән олуғ,
Сән төзәтсәң, без төзәнүрмез қәмуғ.

Игри булсаң, сән төзәлмә*(...)*дин, и тел,
Барчамыз игри булурмыз, – аны бел.

Бәс, ни килсә башқа, бел, телдин килүр,
Адәмиға нә ки қылса, тел қылур.

Кеше йалған сүз билә та*б*ма*с* нәҗат,
Туғры сүз берлә тәбар даим хәйат.

---

[*] Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, бу урында текстка өзеклек кергән. Анда поэма текстындагы 483 нче бәйтнең икенче юлы, 484 һәм 485 нче бәйтләр язылган булган.

Бер хикайәт тыңла имди, и олуғ,
Сүзләрени нәзым *берлә* қылайым қәмуғ.

Бер зәман эчендә бар ирди мәгәр
Бер солтан, ишетеңез б*ер* хәбәр:

Уғлы хален қылды анларға бәйан,
Фикер қылды бик, вәзирләр ул зәман.

Әйделәр кем таңда а*в*ға чығалым,
Шайәд а*в*да сүзләгәй ул – бәқалем.

Таң берлә атланды а*в*ға хасс-у ғам,
[...] тәмам.

[...][*] бу хәбәр:

*19б кәгазь* Очар ирди нагәһан *(...)* анч*а* қаз,
Хуш һауа йөзендә қылдылар ауаз.

Лала салды қарчы*қ*асын ул зәман,
Қазны *тотты* қарчы*қ*асы, и җәуан.

Шаһзадә әйде ул сағәт, ишет,
Бу хәдис мәғнәсени аңла, йегет:

Һәр ки тотды телне – қот*лу*ды ул,
Телне тотмаған уш тотулды ул.

Чөн ишетте ирсә лаласы рәуан,
Шаһ сәв*е*нече тэйү барды ул зәман.

Шаһ сәв*е*нүб бэрде*ләр* хәлғәт*(...)* аңа,
«*Имди* Шаһзадә*(...)* килтүр мәңа».

[*] Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, 501 нче бәйтнең беренче юлы сакланмаган.

Килде ирсә шаһзадә*(...)* үзенгә,
Монтазир ирди шаһ аның сүзенгә.

Ничә кем шаһ лот*ыф* итеб сорды үзен,
Шаһзадә сүзләмәде һич сүзен.

Шаһ қылды лаланы ул дәм таләб,
Хәшем берлә қылды аңа ул ғазәб:

«Кем мәңа йалған хәбәр килтүрд*е*ң уш,
Булдуң имди мөстәхәқ үлмәгә хуш.

Үлтүрүңез тиб бойурды шаһ ани»,
Шаһзадә қәйр*а* әйде сүзени:

«Һәр ки тотты телени – қотулды ул,
Телни тотмаған уш тотулды ул».

Ишетеб уғлы сүзен шаһ булды шад,
Ул мескин лаланы қылд[ы] азад.

Шаһ әйде лотф берлә уғлына:
«Кем бу көн серрең айғыл сән мәңа.

Ни сәбәбдин сүзләмәдең, и уғул,
Мәне қылдың ошбулар зар-у мәлул.

Тәңре хақ*(...)* өчүн айғыл сән мәңа,
Аймаз ирсәң, [...]

*20а кәгазь* Шаһзадә әйде: «И шаһи җәһан,
Бер хәдис үгрәндем ирди ул зәман.

*(Мәңа)* остадым бетиб бирде *(ани)*,
Ошбу ирди *(әйтәйем)* мәғнә*сени*:

Һәр ки тотты телни – қотулды ул,
Телни тотмаған уш тотулды ул.

Күңлүм ичрә әйдем, и шаһи җәһан,
Бу хәдисни сынайын мән бер ғәйан.

Раст булса, мәғнәсен*(...)* сынайын,
Мән хәқиқәт билүб аны, тынайын.

Ул сәбәбдин сүзләмәдем бер зәман,
Ғәфу қылғыл мәндин, әй шаһи җәһан.

Шәрх итәйем сезгә ғаләм солтаны,
Раст ирүр сынадым ирсә *(...)* аны:

Тотса ирди телени сахрада қаз,
Тотмаз ирди ул дәм ичрә аны баз.

Тотса ирди лала ул дәм телени,
Үлмәгәмү бойурур ирдеңез ани.

Күни ирүр бу хәдис, сынадым уш,
Төрки теленчә *(...)* ирүр мәғнәсе хуш:

Һәр ки тотты телени, қотулды ул,
Телени тотмаған уш тотулды ул».

## ТУҚУЗЫНЧЫ БАБ
**самит *(...)* сүзләрен бәйан қылур**

Сал қолақ самитлық ичрә нәу җәуан,
Һәр ки самитдур ирүр *(ул)* пәһлуан.

Күб ирүр бу самитлық*(...)* файдасы,
Тыңла имди, күбдүр *(...)* эшнең файдасы.

Әйде, самит булуң тиб, ул Мостафа:
«Мән сәкәнә сәл*лә*мә вә мән сәмәтә нәҗа».

[...] сәламәт булғай ул,
Самит [...]

*20б кәгазь* Һәр, ки салимдур й*арыйу*р даим *йө*зи,
Мөхкәм *вә* мөстәхкәм булур аның сүзи.

Кем *(...)* самит сүзедин, шаһи җәһан,
Қыл*д*ым имди сүз*(...)*гә тел дәрман.

## ХИКАЙӘТ

Бар ирди Каннуҗда *(...)* пир ник-ү хаһ,
Килүрдин вә*қи*ф вә кичмешдин агяһ.

Үзе назүк иде *вә* күң*ел* кәрим,
Ил ичрә ирди ғалим һәм хәким.

Ултуруб менбәр үзә салим үзи,
Тәңре әмре иде сүзләгән сүзи.

Бер көн үзе вәғз эчендә нагәһан
Кем телендә йөрүде бу сүз рәуан:

«Һәр ки самит булса һәр эшдә үзе,
Кергәй ул дарес-сәлам ичрә үзе».

Тыңла имди бу хикайәтни тәмам,
Аңла имди бу сүзүмни ник-ү нам.

Бар и*(...)*ди мәҗлес эчрә бер җәуан,
Ошбу вәғзне күңлү*ндә* тот*у*ы нагәһан.

Кем ул ичрә булур*де (...)* үзе, –
Мәшһүр ирди самитлық эчрә сүзе.

Бер йәһүди қоңш*ылы*қда бар ирди,
Үзе бәдбәхт-ү йаман әфкяр иде.

Ултурур*де* иркән бер көн самит җәуан,
Килди, азар итди ул бәдбәхт, йаман.

Ошбу Самит пәһлуан назир иде,
Ул йәһүдә қәтле нас қадир иде.

Самит итеб өнәмәде һич сүз*(...)*,
Күңл*е*нә ағыр алыб, чатмады йөз*(...)*.

Йоқлайурда ул кичә Самит җәуан,
Керде төшенә аның шаһи җәһан.

[...] җәуан,
Кем ирдүң са[...]

*21а кәгазь* Кем хәбәр қылды мәңа *ул* Җәбраил,
Йарлықадым тәйү сәни ул җәлил».

Йәнә әйде, ишетең, ул фәхри җәһан:
«Сэкез уҗмах кем сәңа булды мәкян».

Кем бу сүздин шад булдым *(...)* үзүмә,
Кем күрүнмә*с* булды *(...)* шаһ күз*е*мә.

Уйғаныб, возу итеб вақт*ғ*а бақар,
Нагәһан берәгү уш ишик қақар.

Торды, бақты, күрде: ул – җәһүд ирүр,
Әйде: «*И* Самит, мәңа иман үгрәт тәйүр:

Кем мөселман булғам имди *ул* зәман,
Табқай мән анының илә утдин *а*ман.

Динеңез хәқлықыны күрдүм күзүм,
Ошбу диннең хәқлықына йуқ сүзем.

Йатыб уш *(...)* йоқлайурда нагәһан
Кем күрүнде күз*е*мә анда җәһан:

Олуғ, кечек – барчә килмешләр қәмуғ,
Кем йәнаша тезелмеш йэти тәмуғ.

Тотубән анда *(мәне)* килтүрдиләр,
Самитны *(...)*зар иткән бу т*и*диләр.

Фәрман қылды: «Ишет сән, маһе лика,
Атың аны, тиделәр тәмуғ ут*ын*ға».

Қурқуғумдин *сискәнеб т*ордым уш,
Ул сағәт Хәқка иман килтүрдем уш.

Барч*а* малын Хәқ йулунда қылды сарф,
Мундин артуқ *(...)**ти*мәде һ*иҗ бе*р хәрф.

[...][*]
Қаршуңызда сайраб уш тел былбылы,

[...][**]

[*] Бу урында тәнкыйди текстта булган «Баб унунчи. Ғәфу қылмақ сүзләрен бәйан қылур» дигән сүзләр язылмыйча, буш урын калдырылган. Шулай ук кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле 562 нче бәйтнең беренче юлы сакланмаган.

[**] Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, текстка өзеклек кергән. Анда 563 һәм 564 нче бәйтләр язылган булган.

*21б кәгазь* Ғәфу қылмақ ирүр ирнең ирдәме,
Ирдәмендә мең дәм ирүр бер дәме.

Ғәфу қылмақ тәңре бойруқы ирүр,
Бойруқын тотқанға ул җәннәт бирүр.

Хәқ тәғалә буйруқын*(...)* тот рәуан,
Хасс-у ғамдин ғафу қылғыл, и җәуан.

Кем йаманлық қылса сезгә дәмбәдәм,
Сез аңа ихсан б*е*лә қылың кәрәм.

Ғәфу қылмақ берлә булур ир ғәзиз,
Ғәфу қыл барчәдин, и ғәқлы тәмиз*.

Ғәфу *ти*мәк ни *(...)* булур *син* ишет,
Мәғнәсени әйтәйем, аңла, йегет.

Кем кичүрмәк ирүр *ул* бер *(...) без*дин,
Азған вә йазған бәси шәрмән*дә*дин,

Хәқ әй*(...)*үр рәхмәт қылыб анларға *(...)*уш:
«Рузи қылдуқ җәннәт фирдәүсни уш».

Хури ризуан теләгән кеше мөдам
Ғәфу қылсун барчәлардин ул тәмам.

Нагәһан йазыб йаңылса бер кеше,
Кичүрүб андин кәрәм булсун эше**.

Бер хикайәт нәзым итәйем, аңлаңыз,
Җан вә дил берлә сүзен*(...)* тыңлаңыз.

---

* Бу бәйт Ш.Абилов басмасындагы текстта дүрт бәйткә алдарак.

** Бу бәйттән соң тәнкыйди текстта «Хикайәт» (яки Ижевск нөсхәсендә «Әл-хикайәт») дип бирелгән сүз язылмаган.

Кем озағи рузгяр ичрә мәгәр,
Бер мәлик бар ирди әср-ү мөғтәбәр.

Кем аты Мәсғуд и*р*де үзенең,
Шаһы ирди үзе ул йир йөзенең.

Үзләри ғәсри эчендә, и йегет,
Һәм йәнә бер шаһ бар ирди, хуш ишет.

Ибне *Әшгәс* ирди ул шаһ, *(аты)* бел,
[...]*

*22а кәгазь* Табмас ирди бере беренгә зафәр,
Тыңла имди, итәйем уш мән хәбәр.

Ғақибәт Мәсғуд йығды ләшкәрен,
Ил-улусда қуймады оруш ирен.

*Қәвемләр* озун икәгү торуштилар,
Ике ләшкәр күб қатығ оруштилар.

Тәңре тәқдире берлә [на]гәһан ул –
Ибн*е* *Әшгәс* ләшкәрени қырды ул.

[...]**

Алдылар әср*и* улча*(...) (күб) и әмир,*
Ул чәрикдин қылдыла[р] үкүш әс*ир*.

Ғизз-у носрәт берлә *ив*гә килди шаһ,
Ул әсирләрнең *қәумен* йығди шаһ.

---

* Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, текстка өзеклек кергән. Анда 578 нче бәйтнең икенче юлы һәм 579 нчы бәйт язылган булган.

** Бу урында тәнкыйди текстта һәм Ижевск нөсхәсендә булган 584 нче бәйт язылмаган.

Үзе алтун *мөнбәр үзрә* ултуруб,
Сорар ирди барчә бер-бер килтүрүб.

Бер йегеткә төште нагәһан күзи,
Аны ул дәм килтүрүб сорды үзи.

Ул йегет әйде *кем*: «И шаһи җәһан,
Бер сүз*е*м бар – әйтәйем, биргел әман».

Шаһ әйде кем әман бирдем *(...)* сәңа,
Ни сүз*е*ң бар ирсә, айғыл уш мәңа».

Ул йегет әйде кем: «И шаһи *җәһан*,
Сүзүм әйтәйем, ишеткел *нагәһан*.

*Бәс* теләгән эшни бирди Хәқ сәңа,
Хәқ теләгән эшни қылғыл сән аңа.

Носрәт ирди теләгең, – табдың аны,
Ғәфу ирүр сәндин *әйден* теләгән[е].

Хәқ тәғалә сәңа дәвләт бирди уш,
Дошманыңны *(барча)* қәһр қылды хуш.

[...] Хәқлық өчен, шаһи җәһан,
Ғәфу итеб бездән кичүргел бу зәман.

Сән безем йаманымызға бақмағыл,
Қәһр уты берлә безни йақмағыл.

*22б кәгазь* Лотф қылды *(уш)* сәңа пәрүәрдигяр,
Қәһр қылма безгә сән, и нам*и*дар.

Ғәфу итеб қыл күңлүмезни имди шад,
Лотф қылыб барчәмызни қыл азад.

Кем кәримдин даимән кил*е*р кәрәм,
Бәс кәрәм қыл безгә, *и* шаһ, с*и*н бу дәм».

600 Шаһ ул дәм аңлады йегет сүзен,
Күр*ке* сүз әйтүр тэйү үгде үзен.

Қылды айған сүзләрен ул дәм қәбул,
Ул йегетнең қылмады күңлүн мәлул.

Ул йегет сүзени ул дәм ишет*(...)*,
Ул әсирләр*ен(...) исе*ркәб рәх*и*м итеб,

Хәқ ризасы өч*ү*н ул шаһи җәһан
Барчәсын*(...)* азад қылды ул зәман.

Ул йегетни йарлықаб суйурғады,
Ғомре барынчә тыныб хуш ырғады.

*604а Бу китаб[*] хан доғасы берлә тәмам,*
*Қилғанын бәйан қилур мөдам.*

605 И җәһан солтанларының солтаны,
Йэти иқлимда қәмуғ ханлар ханы,

Дөнйаны тултурдыңыз әмән-*а*ман,
Булды рахәт ичрә барчә җисм-ү җан.

Булдуңыз бу көн әманға сез сәбәб,
Кем ирүрсез дөнйа ичрә зилли рабб.

*(...)* Сайәңез*г*ә сығн*у*б килгән кеши,
Ғадлеңез берлә *тәбар* барчә эши.

---

[*] Кульязмада «ти» хәрефенең өстәге ике ноктасы урынына аска бер нокта куелу сәбәпле, «китаб» сүзе ялгыш «кибаб»дип язылган.

Сезгә йари қылды ирсә бариыңыз,
Уш сағәдәт булды даим йарыңыз.

Ни уйун*лә (...)* уйнадылар, от[т]уңыз,
Ғақибәт дөнйаны барч*а* тотту*ң*ыз.

Мәшриқ-у мәғриб сезнең булды тәмам,
Падишаһлар булды уш сезгә ғолам.

*23а кәгазь* Уш мөсәлләм булды сез*(...)* бу җәһан,
Хуш мөсәххәр булды барчә өнсе җан.

Хөкмеңез дөнйаны барчә тотты уш,
Ғәдлеңез*(...)* тулды җәһан*да* имди хуш.

Күрсә ирди ғәдлеңез*(...)* Нәүши*н рә*ван,
Булғай ирди бәндәңез, шаһи җәһан.

Хатәм Тай вөҗүдеңез йөзен күрүб,
Хиҗләт ичрә қалғай ирдиултуруб.

Ул қәтығ йадин уқ атсаңыз *йа*саб,
Бәндә булғай Рөстәм-ү Афр*үа*сийаб.

Уш җәһандағы мөбаризлар қәмуғ
Қолуң*у*з булуб қылур сезгә тәпуғ.

Тәңренең лотф*(...)* ирүр шаһ үзүңез,
Кем ирүр дөнйаға басруқ сүзүңез.

Хөкмеңез берлә төзәнде ил-улус,
Сүзүңез берлә туланды ғәқил-ус.

Дәүләт *вә* фәт*(...)*х-*ү* зафәр берлә мөдам
Сәлтанәт тәхти үзә йөз йыл тәмам.

Ғизз-у дәүләт берлә, *(...)* шаһ, йәшәңез,
Қайда булса дошманыңыз, – түшәңез.

Сезгә кем қылса доғалар дәмбәдәм,
Лотф берлә қыл*ы*ңыз аңа кәрәм.

Ғәрш изеси *йа илаһ*ел-ғаләмин,
Бу доғаны мөстәҗаб иткел, *а*мин.

Бер сүзүм бар – аны тәхрир итәйем,
Мәқсудымны сезгә тәқрир итәйем.

Шаһи ғаләмнең мөбарәк атына
*Күб доға* булсун тиб арығ затына,

Төрк*(...)* нәзым итеб бетидем китаб,
«Нуры содур» аның атыны атаб.

Хәтем қылдым сүзләрени имди *х*уш,
Хәқ мөбарәк қылсун аны шаһға *(...)*уш.

*23б кәгазь* Ничә кем булса җәһанда – *ай-йыл*,
Ничә кем сүзлә*нсә телдә* қал-у қил,

Һәркем аны уқыса һәр дәмбәдәм,
Йа қачан кем бетиса аны қәләм,

Падишаһға даимән қылғай доға,
Җан вә дил берлә үкүш айғай сәна.

И доғаларны ишеткән пак-ү тәк,
Хәзрәтеңдә уш қылыб *й*үзүм н*әҗак*,

Зари берлә м*и*н (доға) қылайым уш,
Лотф берлә иҗабәт қыл аны хуш.

Бу зәман ғазиларының солтаны,
Дөнйа ичрә барчә ханларның ханы;

Шаһи ғаләм ғөмрени қылғыл үкүш,
Йэти иқлимни аңа биргел өлүш.

Дәвләтени қыл җәһанда мөстәдам,
Ғиззәтени қыл зийадә собх-у шам.

Носрәт-ү фәтх *вә* зафәр берлә ани
Қыл сәғадәт ичрә даим, и ғәни.

Бу китабны қыл мөбарәк с*и*н аңа,
Йарлықаб қылғ*ай* ғинайәт уш мәңа.

И кара*н*ғу төнни айдын қылғучи,
И йазуқлар дәфтәрени йуйғучи,

Ғ*афи*р-у *ғаффар* ирүрсән *и* ғәфур,
Мәғфирәт җамыни мәңа син эчүр.

*639а* *Ғәфу қыл йазықларымны и гәфу[р],*
*Йаратқаным, тағәт төнен қыл рәфү.*

Сәңа лаиқ қылмадым һәргиз ғәмәл,
Эшләрем қәмуғ дәға *вә һәм* дәғил.

Дөнйада қылдым үкүш фисқ-у фәсад,
Рәхмәтең*(...)*ә қылдым, и Хәқ, иғтимад.

Ғәрқ ирүр мән мәғсийәт ичрә мөдам,
Булды ғисйан [...]

*24а кәгазь* Тәүбә қылдум, барчә йазуқдин кичеб,
Сән иҗабәт қылғыл имди, йа мөҗиб.

Ғәфу қылыб сән йазуқларым кичүр,
Лотф берлә қәһрүң утыны очур.

Кем ғазәбдин рәхмәтең сабиқ ирүр,
Йарлықамақ сәңа уқ лаиқ ирүр.

С*ине* бер, тиб, белдем имди и, ғәни,
Лотф қылыб йарлықа бу көн мәни.

Йарлықар булсаң, мәнем тәк сад һәзар,
Рәхмәтеңнең тиңезендин ни қ*ор*ар.

Рәхмәтең дәрйасы ирүр *би* гиран,
Йарлықанур қәтрәсендин өнс-*ү* җан,

Күб ғәмәл қылмақ берлә һәрбер кеши
Җәһд қылса дөнйада йаз вә қыши,

Булмағунчә тәңрене, лотфы аңа –
Кермәгәй җәннәткә, қолақ тот моңа[*].

Бер хикайәт қылайым, аңла бу дәм,
Садиқанә *хуш ишет* фәхрел-өмәм.

Җабир Әнсари әйтүр, и җәуан,
Әйде мәңа Хәқ рәсүле ул зәман:

Кем қатымдин хали чықти Җәбраил,
Ул хикайәт мәңа қылды – аңлағыл.

Кем бәни Исраил ичрә мәгәр,
Бер Заһид бар иде хуш мөғтәбәр.

[*] Бу бәйттән соң тәнкыйди текстта һәм Ижевск нөсхәсендә булган «Хикайәт» сүзе язылмаган.

Хәқ йулунда кү*к* оруғыдин килеб,
Гөзләт итте бер җәзирәдә килеб.

Ул [...]ди, бел,
Бөтмеш ирди анда бер тағ, аңлағыл.

[...] ул таг*(...)ди*н бер булақ,
Ақар ирди с*ы*вы балдин татлығрақ.

[...] өстүндә бөтмеш бер тирәк,
Сайәсе бағ Ирәмдин йахшырақ.

*24б кәгазь* Нар *а*ғачы ирди ул тирәк, *и*шет,
Көн дә бер нар бирүр ирди, и йегет.

Заһид ул йирне күрүб қылды мәқам,
Тағәт итде анда даим собх-у шам.

Һәр с*әба*х ул чәшмәгә килүр иде,
Абдәст алыб ул намаз қылур иде.

Ул нар берлә уру*чы(...)*ны ачыб,
Һәр кэчә *ул* чәшмә с*ывы*ндин эчеб,

Иртә-кэчә қылыб ул Хәққа нийаз,
Таңға тигрү қылур ирди күб намаз.

Көндүз уруҗ тотуб ул Заһид мөдам*,
Кичә тағәт берлә биш йөз йыл тәмам,

Ғөмре ахир булды ирсә, нагәһан,
*(Хәқ аңа)* лотф қылды, ишет, җәуан.

Сәҗдә эчрә җаныни тәслим итеб,
Ахирәтг*а* барды дөнйадин китеб.

---

* Бу бәйт юлларының урыннары алышкан.

Чөн қийамәт көне булғанда рәуан
Хә*сд* булса бу хәлаиқ би гөман,

Хәқ тәғалә қылғай *ул* Заһидкә хитаб:
«Рәхмәтем берлә *сезене* йарлықаб,

Бирәйем *(бәһишт) (...)* сәңа җауидан,
Кем тәмуғдин табғул имди хуш *а*ман».

Заһид айғай: «И кәрим *(...)* би нийаз,
Мончә йыллар қылғаным рузә, намаз

Кайда барди, мәңа белдүргел аны,
Йарлықар сән рәхмәтең берлә м*и*не».

Хәқ тәғалә айғай: «И Заһид, фозул,
Рәхмәтемни қылмадыңму сән қәбул.

Мән хисаб итәйем уш сәнең б*е*лә,
Йахшы аңла барч[...]

Йуқдин бар әйләдем, Заһид, *(...)* сәни,
*Кем си*нең аслың [...]

*25а кәгазь* Х*у*р с*ы*в*ы*дин сәни мән қылдым ғәзиз,
Сәңа бирдем сиххәт вә ғәқли тәмиз.

Баш, айақ һәм күз, қолақ бирдем сәңа,
Сән намазың миннәт итәрсән мәңа.

Йити әғзаң төз йарат[т]ым мән қәмуғ,
Кем аның берлә мәңа қылд*у*ң тә*б*уғ.

Ул ғибәдәт қылмаға тәүфиқ йәнә
Рузи қылдым, и фозул Заһид, сәңа».

*Бу хисабның* һәйбәтендин нагәһан
Заһид мескин с*ыв*сағ*ай* ул зәман.

Бер фәрештә сахиб*(...)* Хөс*әйен* җәмал,
Бер қәдәхни тултуруб абе зөлал,

Заһид а*ле*ндин рәуан кичкәй килеб,
Айғай ул Заһид аңа зари қылыб:

[...][*]

Ул фәрештә айғай: (И) Заһид, мәңа
Тағәтең биргел, бирәйен с*ы*в сәңа.

Заһид айғай: «*(...)* Йөз йыллық тағәтем
Бирәйем кем, йуқтур үзгә тақәтем».

Ул фәрештә қылмағай аны қәбул,
Йадағай Заһид булуб ул дәм мәлул.

Ғақибәт Заһид су*(...)*салықындин й*өдә*б,
Барч*а* қылған тағәтен аңа атаб,

Киткәй үзе *(...)* дөнйадин тилмүрүб,
Тағәте*(...)* бер эчем с*ы*вға т*и*гшүрүб[**].

У*(...) қ*әдәхни алыб эчкәй ул зәман,
Тағәтендин би нәуа қалғай һәман.

Қылғай ул дәм хәзрәте ғиззәт хитаб,
Кем, айа, Заһид, мәңа айғыл җәуаб:

---

[*] Бу урында тәнкыйди текстта һәм Ижевск нөсхәсендә булган 682 нче бәйт язылмаган.
[**] Бу бәйт белән аннан соңгысының урыннары алышкан.

[...] тағәт иткәнең қәмуғ
Бер эчем с*ы*вға сатыб, қалдуң қоруғ.

[...]гә кергел рәуан».
Зари қылыб, Заһид айғай ул зәман:

*25б кәгазь* «Барч*а*ны йуқдин йаратқан пак-ү тәк,
Белдем үзүмни, мәне қылма һәлак.

Китти *г*өмрүм ичрә қылған тағәтем,
Тәмуғ ичрә йанмаға йуқ тақәтем.

Кем йараттың мәне син әср-ү зәғиф,
Лотф қылғыл мәңа бу көн, и л*ә*тиф.

Рәхмәтең берлә мәне с*и*н йарлықа,
Рузи қыл лотфың берлә мәңа лиқа.

Лотф*(...)* берлә қылмасаң мәңа нәзар,
Булды *и*шләрем қәмуғы зир-зәбәр».

Хәқ тәғалә айғай: «И Заһид, бу дәм
Рәхмәтем берлә сәңа қылдым кәрәм.

Барғыл уш җәннәткә имди би гөман,
Рузи қылдым сәңа хуш хури җинан.

Қыл тәнәғғем анда күб ниғмәт б*е*лә,
Йарлықадым сәни мән рәхмәт б*е*лә».

Йа иляһел-ғаләмин, имди бу дәм
Тәүбә қылыб барчәмыз қылдуқ нәдәм.

Хәзрәтеңдин теләнү килдүк қәмуғ,
Рәхмәтеңдин безни қайтарма қоруғ,

Кем ирүрмез тағәтеңдин бинәуа
Лотф берлә безгә қыл рәхмәт ғәта.

Рәхмәтең берлә булур эшләр тәмам,
Рәхмәт иткел барчәмызға, вәс-сәлам.

И қәмуғ ханлар ичрә *(...)* намдар,
Кем ирүрсез дөнйа ичрә ка*ид*кар.

Қәһр берлә дошманыңыз сынды уш,
Лотф берлә дусларыңыз тынды уш.

Рахәт ичрә ил-*(...)*ус булды қәмуғ,
Имди тынды дөнйада ке[...]

Уш сезнең булды җәһан, и падишаһ,
Сезгә булды [...]

*26а кәгазь* Мәшриқ-у мәғриб қәмуғ имди уш,
Зәвеқ табти барч*а*лари имди хуш.

Хуш мөшәррәф булды уш*ал* руйи зәмин,
Булғай сезғә сәғадәт һәмнишин.

Күб й*ә*шәңез д*әв*ләт эчендә мөдам,
Ғомреңез булсун җәһанда мөстәдам.

Күңлүңез теләкләрен бирсүн Иляһ,
Иртә-кичә сезгә булсун *(Хәқ)* пәнаһ.

Үтенәйем сезгә уш шаһи җәһан,
Д*әв*ләт эчендә й*ә*шәңез күб з*ә*ман.

Атыңызға нәзым қылғаным китаб
Хәтем қылдым, аны мән төрки йасаб.

Тигмә бер бәйти ирүр берендин хуш,
Сүзләри вәғз-нәсыйхәт ирүр уш.

Уқ*у*ған ғақил кешеләр аңлағай,
Бу зәғиф бичарә қол*(...)*н*ы* таңлағай.

Тигмә йирдин җәмғ қылыб сүзләрен,
Мона күргүздүм мәғани йүзләрен.

Тәрҗемә қылыб парсы телен, *и*шет,
Нәзым қылдым төрки теленчә, *и* йегет.

Йил тәк исеб кичсә ошбу рузгяр,
Дөнйада қалғай бу сүзләр йадгяр.

Кем уқ*у*р булса аны пир-ү җәуан,
Теләгем улдур үзендин ул зәман:

Ханға қылғай даимән үгүш доға,
Мәғнә аңлаб, табса *ул* сүздин сафа.

Хан доғасы йөрүгәй телләр үзә,
Важиб ирүр [...]

Кем һәмишә ханға қылғайлар доға,
Төне-көне [...]*

*26б кәгазь* Нагәһан бер қол доғасын ул кәрим
Мөстәҗаб иткәй гөмансыз ул хәким.

Ул доға берлә булуб *и*шләр тәмам,
Дә*в*ләт ичрә күб йәшә*га*й шаһ мөдам.

---

* Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, текстка өзеклек кергән. Анда 722 нче бәйтнең икенче юлының ахыры һәм 723 нче бәйт язылган булган.

Имди *(...)*уш васф*е* халем әйтәйем,
Бер теләгем бар аны йад итә*л*ем:

Чөн *сынадым* ирсә дөнйа *и*шени,
Белдем аның фетнә вә тәшвишени:

Би вәфа ирмеш бу дөнйа – аңладым.
Әсри күб ирмеш җәфасы – таңладым.

Аны таңлаб ултурурда нагәһан
Хатеремғә төшти фикрәт ул зәман.

Кем мөбарәк Урд*а*ға барса*(...)* үзү*м*
Х*ан*ның қотлуғ йөз*е*н күрсә күзем,

Ул дәм ичрә күб доға қылғай ирдем,
Йар*л*ылықым сүзени айғай ирдем.

Қылғай ирди йарлықаб мәңа нәзар,
Қ*а*йра булғай ирди эшем мөғтәбәр.

Тигәй ирди теләкем барча рәуан.
Кем ғинайәт қылса ул шаһи җәһан.

Ни қылайым *(...)* көчүм йуқдур, дәриғ,
Кем ирүр мөфлислек иргә бәс қәтиғ.

Ханға лаиқ һич [...] йуқ бүләк,
Урд*а*ға бармақға һәм қ*уү*әт кәрәк.

[...] қалдым бер зәмән,
Хәқ тәғалә лотф қылды нагәһан.

[...] *шәйх* хитаб,
Кем аның сүзе берлә төзедем китаб.

[...]зе
Бу ирүр [...]*

*27а кәгазь* Тасниф иткел төрки теленчә *бер* китаб,
Падишаһ атыға аны хуш йасаб.

Кем Сөләйман йа*ң*лиғ ирүр хәзрәти,
Мөстәдам булсун җәһанда дә*в*ләти.

Һич нимә*(...)* ихтийажы йуқ *д*орур,
Хезмәтендә барч*а*си ануқ торур.

Дөнйа бе*р пулча* күрүнмәз күзенә,
Сән қым*у*рысқа йа*ң*лиғ имди үзенә.

Ул китабың үтүнеб *йа*зғыл рәуан,
Рәх*и*м қылғай *кем* сәңа *(…)* шаһы җәһан.

Рәх*ме* берлә эшеңез булғай тәмам,
Рахәт иткәйсән һәмишә, вәс-сәлам».

Чөн күң*л*үл*(...) шәйхе* сүзен тыңладым,
Ни ишарәт қылды ирсә – аңладым.

Қәзғудин булды хәлас ул дәм күңүл,
Ғашиқанә сүз*е*ни қылды*м* қәбул.

Алдым *и*лкем*г*ә қәләмни ул зәман,
Телгә ни кем килсә күңүлдин рәуан,

Бетийү башладым ул сағәт қәмуғ,
Ғишық берлә тыңла, и кечек-олуғ.

* Кульязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылган булу сәбәпле, текстка өзеклек кергән. Анда 738 нче бәйтнең беренче юлы тулаем һәм икенче юлы өлешчә укылмый, ә 739 нчы бәйт сакланмаган.

Бер хикайәт қылайым сезгә бу дәм,
Нәқеш итә ка*г*әз *үзә* аны қәләм[*].

Бер хикайәт қылайым, ғаләм *жҫ*аны,
Йалған ирмәс, күни, тыңлаңыз аны.

Рауилар*(...)* аны риуайәт қылыр уш,
Сидық берлә ишетеңез барчә хуш.

Дауд уғлы ул Сөләйман, Хәқ рәсүл,
Бикләрени йиғды бер көн барч*а* ул.

Өндәде ул көн вәзирләрен мәгәр,
Туй булур диб қылды барч*а*ға хәбәр.

[...] вәзирләр килдиләр,
Ул зәманда бер олуғ туй қилдилар.

*27б кәгазь* Ил-улус*(...)* килди қәмуғ йыйғылыб,
Тигмә бере бер л*о*т*(...)*ф т*и*г*и*ш алыб.

Төр*лүк* таңсуқ күп т*и*г*е*ш килтүрдиләр
Тигмәси *озақдин белдүрделәр*.

Бик, вәзирләр ултурурда ул зәман –
Ул олуғлар арасында нагәһан

Килди бер турғай йырақ йирдин талыб,
Бер са*нычқа* б*от*ын ағзы*н*ға алыб.

Әйде кем: «булсун мөбарәк ошбу туй,
Хасил *қылу* белмәдем һи*жҫ* йылқы, қуй.

И, Сөләйман, ошбу ирүр табқаным,
Җәһд берлә туйға хасил қылғаным.

---

[*] Бу бәйттән соң тәнкыйди текстта булган «Хикайәт» сүзе язылмаган.

Дөнйа*да* ирүр қанәғәт тәк эшем,
Халемә күрә*(...)* ирүр уш т*игеш*ем».

Ул нәб*иул*лаһ Сөләйман, и йегет,
Чөнкә турғай сүзен аңлады, ишет.

Ғөзрени лотф б*ер*лә қылды қәбул,
Булмады турғай сүзендин һич мәлул.

Ул дәм уқ турғайны ул суйурғады,
Йар*л*ы турғай *ив*гә барыб ырғады.

Мән тәқи имди, әйа шаһ җәһан,
Булдым ул турғай мәңизли*к ул* зәман.

Хәзрәтенгә йар*лы*лықым белдүрүб,
Уш мона табқан т*игешү*м килтүрүб,

Хәзрәтеңез *ул* Сөләйман тәк ир*ү*р,
Дөнйаның таңсуқлари сездә *тору*р.

Уш көчүм йетәрчә төрки китаб
Нәзым қылдым падишаһ атын атаб.

Лотфыңыз*лә* қылсаңыз аны қәбул,
Хәстә күңлүм булмағай ирди мәлул.

Қылғай ирдем *(...)*җан *барынча* мән доға,
Айғай ирдем җан вә дил [...]

*28a кәгазь* И кәрим *вә* пак-ү тәк *вә* кәрдигяр,
Хәзрәтеңдә йалбарур фәқир Мөхәммәдйар.

Тәңре фәзл*(...)* берлә булды бу тәмам,
Белең имди мони сез, *(...)* хасс-у ғам.

Туқуз йөз қырқ сәкездә тарих*дур*,
Китабым хәйр илә булды мөхәррәр.

Ишет *и*, мөғтәбәр ханлар ханы,
Сәкез йөз иллег биш бәйт ирүр саны.

Илаһи, бу китаб булғай мөбарәк
Б*и* хәққи *Ғ*әм*м* вә Ихляс *(…)* Тәбарәк.

Тәүәккәлна ғаләл-лаһи әман*ән*,
Тәүәжҗәһна иләл хәққи *зәманән.*

Ушал көн*(...) кем* с*әвәд* иттем бу тәқрир,
Хийалым нәқш*ә* бағлап ошбу тәхрир.

Күңүл гәнҗидә бар иди *анжҗа* гәнҗ –
Ки йыллар қылғай ирдем сарф рәнҗ.

Н*ә* мәғнә*гә* мо*ңы*, нә сүзгә фикре,
Н*ә* мәғнәдин, *нә* сүздин үзгә фикре.

Бул*у*б мәғрур үз*(...)* гәнҗ*е*сенә –
Н*ә* мохтаҗ үзгәләрнең [...]*тә*сенә.

Вәли чөн хөкем иде ул шаһ җәһандин,
Кем қылғай тәрҗемә ул *тәрҗем*андин.

Төрки рәсм*(...)* берлә би тәкәллеф
Зарурәт монч*а*лық қылдым тәсаррыф.

Тәүәққоғ улдур әрбабы һөнәрдин,
Ки чөн [...] алсалар [...]

С*и(...)*ғайлар мөхиб*(...)* бинәуаны, –
Доға [...]

Йәнә дәр-хас*и*м бар йахшилардин, –
М*әгқүл сүзене* бе[...]

[...]
Тәсаррыф берлә сәрасәр [...][*]

*28б кәгазь* Уқығанға, бетигәнгә, илаhи,
Мөбарәк қыл бу гәнҗ падишаhи.

790 *Җөмадел-ахыр* айының *егермесе*
Ки булды бу китабның интиhасы.

*Вә* фәқир*е* кем җәфа берлә бетиде,
Доғаи әhел *әйләрдән* өмиде.

Тәмам булды «Нуры содур» китабы,
Нәдүр фәқир йазғучының гөнаhы.

[*] Кулъязма кәгазенең түбәнге өлеше ертылып төшкән булу сәбәпле, 787 нче бәйтнең беренче юлы укылмый һәм 789 нчы бәйт сакланмаган.

## *ИЖЕВСК НӨСХӘСЕ*

*1а кәгазь* Бер хәдис мәғнәсен әйтәйен сәхих,
Җан вә дил берлә ишеткел уш сәрих.

Рәхмәт иткәй күкдәге*ләр* сезгә хуш,
Даим артар дә*в*ләтеңез имди уш.

Бу хәдисни ишет, фәхрел-әнам,
Рәхем қылғыл барч*а*ларға дәмбәдәм.

Кемгә кем дәүләт, сәғадәт йар ирүр,
Тәңренең қоллариғ*а* йари бирүр.

*Б*ары*й* аңа йари қылур һәр зәман,
Дөнйа ичрә күрмәз ул һәргиз *йаман*.

*1б кәгазь* Бақи қылур тәңре аның дәүләтен,
Даим арт[т]*у*рур Хәқ тәғалә ниғмәтен.

### *ӘЛ-ХИКӘЙӘТ*

Ул рәсүл*ул*лаһы Муса, аңлаңыз,
Қылды ул бер көн мөнаҗ*а*т, тыңлаңыз.

Зари берла қылды хәзрәткә нийаз,
Ул нийаз берлә әйд*е* Хәқ*қ*ә раз.

Кем йаратқан пак-у тәк вә и ғәни,
Ни сәбәбдин ихтийар ит[т]ең мәни.

Кем мәңа бирд*е*ң рисаләт хәлғәтен,
*2а кәгазь* Рузи қылдуң уш мөнаҗ*а*т дә*в*ләтен.

Лотф берлә қыл аны мәңа бәйан,
Кем мәңа булсун бу мәғнә ичрә ғәйан.

Ул дәм ичрә қылды Хәқ аңа *г*итаб,
Кем, айа Муса, ишеткел уш җәуаб.

Кем безем пәйғәмбәремез *ул* Шөғәиб,
*Буйругыма* садиқ ир*де ул* биғәйб.

Үзе чөн кем бирде сәңа қызыни,
Сән қәбул қылд*у*ң үзеңә сүзени.

Кем аның қуйларын*ы* көтәр идең,
*2б кәгазь* Вәғдәсени *йиткүрүб* китәр идең.

Хезмәт итеб сән үз*ү*ңә ул заман,
Қуйларыни көтә башладуң рәуан.

Шәфқәт и*теб* қуйларын көтәр идең,
Тазә утлар истәйү китәр идең.

Вақты берла *сурар* ирдең һәр берен,
Барч*а*сының аритур ирдүң йерен.

Бу йусунлуғ көтәр иркән сән ани,
Әсри имгәтте ушал бер қуй сәни.

Кем сачыл*ы*б чықты қуйлардин рәуан,
*3а кәгазь* Қач*т*ы ирсә, қудың аны ул заман.

Күб йөкүрдүң, һич арыб ултурмад*ы*ң,
Арығаныңны кешегә белдүрмәд*е*ң.

Ул қуй арыды, ғақибәт тот[т]*ы*ң аны,
Рәхим қылыб ул дәм *өретең* аны.

Әйдең аңа: и мөбарәк җануар,
Күб йөгүрдүң сән қачыб, ар*ыды*ң мәгәр.

Үзүң арыб һәм мәне арғуздуң уш,
Бер зәман қылғыл асайеш имди хуш.

Тунуң ичрә чолғаб аны, күтүрүб
Килд*е*ң ул дәм қуйларыңа тигүрүб.

*3б кәгазь* Рәхем қылд*ы*ң ирсә, и Муса аңа,
Рәхмәт ит[т]ем мән тәқи ул дәм сәңа.

Ихтийар итеб сәни қылдым қәбул,
Ла-җәрәм булдуң җәһанда Хәқ рәсүл.

## ӨЧҮНЧЕ БАБ
### Сәхаүәт сүзләрен*е* бәйан қылур

И сәхаүәт мәғдәненең җәүһәри,
И сәғадәт тиңезенең гә*в*һәри.

Уш сәхаүәт бабыны қылыб бәйан,
Көч йетәрчә қылайым бар*җ*а ғәйан.

Тыңлаңыз имди сәхәүәт сүзләрен,
*4а кәгазь* Т*аки* күргәйсез сәғадәт йөзләрен.

Кем сәхаүәт берлә булур ир сәғид,
Ул сәғадәт даимән булур мәзид.

Қайу ир кем (булса) дөнйада сәхи,
Хаша булмас ахирәтдә дузәхи.

Кем сәха*үәт* ирүр иргә олуғ һөнәр,
Ул һөнәр ирүр кешегә *таҗ вә* сәр.

И мәҗлес эчрә ултурған тәмам,
*4б кәгазь* Ишетеңез ошбу сүзни хасс-у ғам.

Җәһан эчендәге ғәйбләр қәмуғ
Бер кешедә булса бар*җа*, и олуғ,

Бар*җа* ғәйбләрни сәхаүәт йабар,
Һәркем иксә даим ғиуазын тәбар.

Хәқ зийад*әт* қылур аның малыни,
Ахирәтдә хуш қылур әхуалени.

## Ә*Л*-ХИКАЙӘТ

Бер хикайәт қылайым уш, тыңлаңыз,
Кем сәхи васфыни хуш аңлаңыз.

*5а кәгазь* Ул борунғи рузгярда, и йегет,
Бер хәммал бар ирди, хуш *и*шет.

Вақты ирди үзенең әсрү *бәтер*,
Һ*иҗ* нәмәрсәсе йуқ ирди, и әмир.

Қыйаға барыб, к*и*лтүрүр ирди утун,
Арқасы берлә күтүрүб тигмә көн.

Сатар ирде ике данкигә ани,
Ул тәсәддық қылур ирди берени.

Йәнә бер данкисен үзе алыб,
Хәреҗ итәр ирди *ив*енгә барыб.

*5б кәгазь* Бер көн утун сатыб *(...)* нагәһан
Барур ирди йулда күрде бер җәуан.

Бер кеше аны тотуб қатығ орур,
Ул йегет мескин ойалыб тик торур.

Хәммал әйтүр аңа: «Кем бу ни торур,
Н*и* сәбәбдин сәни бу кеше орур?».

Ул йегет әйде: «Кем әйтәйем сәңа,
Ике данки буру*җ*луғ ирүр мән аңа».

Ишетеб хәммал бу йегет сүзени,
Алды *ул* буру*җ*луғ қулундин үзени.

*6а кәгазь* Сатқан утун бәһасен бирде аңа,
Уғлы, қызы қалды а*җ* – барч*а* йәнә.

Иртәсе хәммал мәгәр тағға барыб,
Утун алыб к*и*лтүрүр иркән арыб;

Бер кешене күрде кем балық сатар,
Һи*җ* кеше алмаз балықын, ғәйб итәр.

Мәсхәрә тотуб аны тигмә бере:
«Ул изелмеш балықың килтүр бире», –

Тэйү аңа, көлүшүр ирди қәмуғ,
Ул базар эчендәге кечек *(...)* олуғ.

*6б кәгазь* Ул балықчы *барды* ирсә рәуан,
Килде ул хәммал қаты*ңа* ул зәман,

Әйде: «И утунчы, тыңлағыл сүзүм,
Бу балық берлә қарарды бу к*ү*зүм.

Сатсам аны – һи*җ* кеше алғусы йуқ,
Имди мәндин алғыл аны уш сән уқ.

Балық алыб, *(мәңа)* бэргел сән утун,
*Ивү*ңә барыб ашағыл *(...)* бөтүн.

Сәндин үзгә һ*ижҗ* кеше алмас *мо*ны,
Лотф итеб, андин хәлас иткел мәне.

*7а кәгазь* Қылды хәммал анын сүзени қәбул,
Утун*(...)* биреб, балықны алды ул.

Ул балықчы сәвүнүб барды рәуан,
Имди ишеткел хикайәт, и җәуан.

Килде хәммал *ив*енгә әсрү арыб,
Әйде кем *бешүр* ошбу балық қарнын*ы* йарыб:

«Қылайым уғланларым өчүн тәғам,
Күргел имди тәңренең лотфын тәмам».

Йарды ирсә ул балықның қарныни,
Бер данә чықты кем, *хәммал* булды ғәни.

*7б кәгазь* *Әйләде* данә лотф вә шаһуар,
*У рәушандин балқур кичә шислар.*

Йөз мең алтун ирди анын қиммәти,
Йатмыш ирди – қубты хәммал дәүләти.

Аз нәмәрсә берлә қылды ул сәха,
Хәқ ғиуаз*(...)* бирде аңа үкүш ғәта.

## ТҮРТ*Е*НЧЕ БАБ
### хәйа сүзләрен*е* бәйан қылур

И хәйа бағының ул тазә гөле,
Хәзрәтең ирүр сәғадәт мәнзиле.

Ишетеңез уш хәйа бабы сүзен,
*8а кәгазь* Ир хәйа берлә күрәр дәвләт йөзен.

Һәркем ул дәүләт теләр булса мөдам,
Ихтийар итсүн хәйаны *ул мөдам*.

Кем хәйа берлә сәғадәт йар ирүр,
Ул сәғадәт хасил*(...)* дидар ирүр.

Һәр кем құрқса тәңредин ул ойалур,
Дөнйасыны биреб ул ғоқба алур.

Булур иман ул кешенең хасилы,
Җәннәт ирүр ахирәтдә мәнзиле.

Ул *кем* ойалса тәңредин қылмаз йаман,
*8б кәгазь* Һич кем ирсәгә ул тигүрмәз зийан.

Кем эчендә сақлар ул ойатыни,
*И*згүлүк берлә чықарур атыни.

Қайу кем ирсә ойалса тәңредин,
Ни бойурса чықмаз аның әмредин.

Барча йердә Хәқны ул хазир белүр,
Һич йаман эш қылмаз, үзе ойалур.

Даимән күрәр үзени шәремсар,
Үзенгә үзе һәмишә йул кэсәр.

Хәқ йулында күнилек берлә йөрүр,

[...][*]

---

[*] Бу урында кулъязманың бер кәгазе төшкән. Анда поэма текстындагы 230 бәйтнең икенче юлыннан алып 240 нчы бәйтнең беренче юлына кадәрге өлеше язылган булган. 8б кәгазьдәге кустод: *күни*.

*9а кәгазь* Бу хәдис ирүр кем әйде Мостафа.

Бәс хәйасыз кешенең иманы йуқ,
Бихәйалық дәрд ирүр, дәрманы йуқ.

Кем ойатсыз кешедин килүр йаман,
Һ*иҗ* ойалмас, тэгүрүр илгә зийан.

Һәр кем ул қурқса, ойалса тәңредин,
Бер сағәт хали булмас *ул* әмредин;

Гәр ту күңүл берлә ул тәүбә қылур,
Хәқ қатында ул гөнаһларын *бел*үр.

Һәр кем ирсәни *уйа*тмас ул кеши,
*9б кәгазь* Даимән лотф-у кәрам булур эши.

## *ӘЛ-ХИКАЙӘТ*

Бер хикайәт қылайым сезгә бәйан,
Кем җәһан эчендә сүзләнүр ғәйан.

Озақ*ы* кичкән зәманда, и йегет,
Бер ғәрәб бар ирди, әйтәйем, ишет.

Ул ғәрәбнең йирен, йортын аңлаңыз, –
Бар*җ*әси шурстан ирди, тыңлаңыз.

Кем шур ирди с*ы*влары аның,
*И*чәр ирди *сәвен*үр кечек, олуғ *сыв*ларың.

*10а кәгазь* Белмәс ирдиләр сөчүк с*ыв*ны *т*уға,
С*(...)*вны *ш*урса қ*ой*нур ирдиләр уға.

Бу йусунлуғ торур иркән ул ғәрәб,
Нагәһан булды аңа бер эш ғәҗәб.

Йағмады анларға йағмур бер зәман,
Утлары бетмәде, қылдылар фиған.

Йазылар эчрә һи*җ* ут қалмады,
Үзләре эчкүгә с*ыв* таб*у*лмады.

Күчтиләр *ул* йортдин анлар қәмуғ,
Тигмә йару барды*(...)* кечек *һәм* олуғ.

*10б кәгазь* Ғәрәб тазә *(бер)* йазыға к*и*лде мәгәр,
Әйтәйем ул йазы васфындин хәбәр.

Күрклүк йазы ирди, таза утлары,
Утлар ирди һәр тарафда атлары,

Хөррәм тазә, йәш *ут* ғәләфдин төзәнүб,
Төрлүк сә*җ*ак берлә имди бизәнүб,

Һәр тарафда *йи*тмеш ул *җайер* чәмән,
Күрсә кем җәннәт ирүр ул зәман.

Таңлар ирди йөрүр иркән ул ғәрәб,
Қылур ирди ул йазыда су таләб.

*11а кәгазь* Йөрүр иркән йазы ичрә, и олуғ,
Күрде бер күл: эче балчық, с*ыв* тулуғ.

Сусамыш ирди *(...)* ғәрәб би гөман,
Эчте ул балчықлы судин нагәһан.

Ләззәт алды *(ул)* с*үч*ек судин ғәрәб,
Эчте ирсә нагәһан қылды ғәҗәб.

Әйде кем булғай бу *бе*р җәннәт мәгәр,
Кем ишетмеш ирдем андин мән хәбәр.

Хәузы кәүсәр ошбу булғай, күрдем уш,
Кем ирүр сувы бу йәңлиғ татлы, хуш.

*11б кәгазь* Татлы су эчкәне йу*қ* ирди ғәрәб,
Таңлаб аны қылды ул әср-ү ғәҗәб.

Бер сынуқ күзәсе бар ирди һаман,
Аны ту*(...)*турды ушал су*(...)*дин рәуан.

Бер киезгә *мөхкәм* аны *(...)* хуш чолғады,
Йебләр ишеб *(аны)* мөхкәм бағлады.

Әйде кем: «килде мәңа дәүләт бу көн,
Әрмаған илтәйен аны шаһ өч*ү*н.

Тэгүрәйен мән хәлифәгә аны,
Кем эч*е*б кәүсәр с*ы*вын, тынсун җаны».

*12а кәгазь* Тәүәсенгә йөкләде су*(...)*ны рәуан,
Тә*в*әгә *(...)* менде үзе ул зәман.

Кэчә-көндүз ойумады йул йөрүб,
Ашы*ғ*ыб тәүәсени қатығ сөрүб[*].

Чықты ул *йазы*дин мескин ғәрәб,
Җәһ*әт* итеб қылды хәлифәни таләб.

Т*ак*и ул көн шаһ*(...)* ав*ғ*а атланыб,
Сәйд қылу йөрүр ирди имгәнеб.

Йөрүр иркән шаһ*(...)* күрде нагәһан,
Кем йырақдин т*ө*з күрүнде ул зәман.

---

[*] Бу бәйт белән аннан соңгысының урыннары алышкан.

*12б кәгазь*

Тәүәдин төшмәс иркән ул би-әдәб[*],
Тәүәсен қатығ сөрүб йет*[т]*и ғәрәб,

Падиша*(...)ға* қылды ул дәмдә сәлам,
*Сақунур* иркән сүзен әйде тәмам:

«Кем сәңа к*и*лдем, хәлифә, бу зәман
М*о*на килтүрд*ү*м ғәҗаиб әрмаған.

Кеше андақ әрмаған күргәни йуқ,
Уш мона килтүрд*ү*м аны сәңа уқ.

Хәқ зийадә қылсун ғөмреңни, и шаһ,
Сәңа җәннәт с*ы*вины килтүрдем, аһ.

*13а кәгазь*

Эчкел аны, *и* хәлифә, бил-ләһи уш,
Кем йөрәкең тазә булсун имди хуш.

Эчеб аның ләззәтени аңлағыл,
Мәңа инғам, күб н*има* бағышлағыл».

Ул с*ыв* хален күзә эчендә, ишет,
Эссе көнләр ирде, аңла, и йегет:

Сасы ирди йызығы, исе йаман,
Тулды шаһ*ның* наз*ү*к дәмағы ул зәман.

Ойалыб ул с*ыв*ны алды иленә,
Нагәһан тикүрде аны теленә;

*13б кәгазь*

Күңли болғанды хәлифәнең рәуан,
Серрени қылды қәмуғлардин ниһан.

Әйде: «Җәннәт с*ы*вы ирмеш, аңладым,
Бу ғәрәб айған сүзени тыңладым.

---

[*] Бу бәйт юлларының урыннары алышкан.

Бир*де(...)* мең алтун инғам үзенә,
Ғәйб қылмаңыз аның сез сүзенә.

Вәли үзе мундин уқ қайтсун рәуан,
Килмәсүн ул безем илә нагәһан».

Шаһ сүзе берлә қайт*[т]*ы теркенчә ул,
Тәүәсина мүнүб ул дәм тот*[т]*ы йул.

*14а кәгазь* Сордылар *(...)*: «Ни с*ер* ирди, падишаһ,
Кем ғәрәбни қылдыңыз м*о*ндин *бер аһ*».

Падишаһ вәзиренгә әйде җәуа*н*.
Ул ойалыб булмасун тэиб хәраб:

«Бу Форат с*ыв*ын килүб кэчсә иде,
Сусаб аның суыни эчсә иде;

Бәс ойалғай ирди *(...)* кылғаныдин, –
*Йан*ғай ирди сүзе йалға*(...)*дин.

Безни йитеб килгән кем ирсә ойалыб,
Үзе қылған эшедин хәйран қалыб,

*14б кәгазь* Барса ирди, ни рәуа булғай иде,
Биргәнемезни әсиғ қылғай иде».

Чөнкә б*и*кләр шаһ сүзен тыңладылар,
*(...)* ни кәрәм қылғанын аңладылар.

Җан вә дил берлә қылыб үкүш доға,
Падишаһға әйделәр йөз мең сәна.

## БИШЕНЧЕ БАБ
## **ғәза*т* *[...]* сүзләрен*е* бәйан қылур**

*Қалә г[аләй]һ[иссәла]м: «Рәҗәгна мин җиһадил-ахирәти»*

И җәһан ғазиларының сәрүәри,
Сез ирүрсез дин *(...)* дөнйа миһтәри.

[...][*]

*15а кәгазь* Кем қылур *(анлар)* хәлаиққа җәфа,
Бу сәбәбдин аны әйде Мостафа:

«Һәр кем ул қылса хәлаиққа зийан,
Мәғнә ичрә ирүр ул ғәқрәб-чайан.

Кем зийанкяр кешени үлтүрсә, бел,
Йылан үлтүргән тик ирүр, – аңлағыл».

Дин*гә* дошман*(...)* даимән кяфир булур,
Ғазилар кяфир билә туқуш қылур.

Әнбийанең сыйфаты ирүр ғәза,
Кемгә кем қылса аны тәңре ғәта;

*15б кәгазь* Дөнйада олуғ кәрамәт ирүр ул,
Кем аның берлә тәбар җәннәткә йул.

Ул рәсүл*ул*лаһ мөбарәк ләф*з*ыдин,
Кем рәсүл садиқ ирүр, фәхре дин.

Нәқел итәйем бер хәдис*е* мөғтәбәр,
Мәғнәсендин қылайым сезгә хәбәр.

[*] Бу урында кульъязманың бер кәгазе төшкән. Анда поэма текстындагы 299 нчы бәйттән алып 307 нче бәйткә кадәрге өлеше язылган булган. 14б кәгазьдәге кустод: *қылайым сезгә.*

Мәғнәсе бу ирүр, аңла, и йегет,
Төрки телен*җә* әйтәйен, йахшы ишет.

Җан вә дил берлә ишет, қыл қәбул,
Кем мөбарәк ләфзыдин әйде рәсүл:

*16а кәгазь* «Хәқ тәғалә қылды м*и*нем ризқым уш,
Бу сөнгүм күләткәсе *астында* хуш.

Йәғни кем ризқымны қылды ул уған,
Бу ғәза малындин, аңла, и җәуан.

*319а* *Кем ғаза малы ирүр әср-ү хәлаль,*
*Алса кяфер малыны булмас вәбаль**».

Кем ғәза ирүр рәсүлнең сифати,
Артар аның берлә ислам дә*в*ләти.

*Һәр*кем эшләсә рәсүл эшен*(...)* мөдам,
Дин вә дөнйа эшләри булур тәмам.

*16б кәгазь*

## Ә*Л*-ХИКАЙӘТ

Бер хикайәт нәқел итәйем мөғтәбәр,
Кем Хәсән Басридин ирүр бу хәбәр.

Үзләри әйде к*и* күрдүм бер йегет,
Ғазил*а*рдин ирди үзе, хуш ишет.

Ул хикайәт қылды мәңа, тыңлаңыз,
Ғазилар әхуалени хуш аңлаңыз.

Кем тэңиздә йөрүр ирдүк бер зәман,
Ғазилық қылыб җәһанда нагәһан,

* Кулъязмада бу сүз ялгыш «вәбали» дип язылган.

Йелләр эсиб қайнады бер көн тәңиз,
*17а кәгазь* Ғәрек булды тәңиз ичрә кәмәмез.

Бер ағ*аҗ* өстүндә мәне йел алыб,
Бер җәз*а*ир*(...)* ичрә чықарды салыб.

Ул җәзирә утлары зәғфәран иде,
Күрклүкдә җәннәти ризуан иде.

Ул җәзирә уртасында бер сарай,
Кем йырақдин нуры балқыр қыш вә йай.

Тамлари *бер* кербе*җ* – алтун, *бере* көмүш,
Дөрре-җәүһәр ул сарай ичрә үкүш.

Кердем ирсә ул сарайға мән рәуан,
*17б кәгазь* Күрдем анда кем йатур бер қа*җ* җәуан.

Сач, сақаллары таранмыш, тазә уш,
Тунлари пакизә һәм үзләри хуш.

Ул сарай анлар билә пөр нур иде,
Үзләри анда йатыб ойур иде.

Күрүб анлар халени қуркдым, и йар,
Ташқару чықд*у*м, күрәрмән бер сәуар:

Ул ирүр хөсн җәмалда би нәзыйр,
Йызығы ирүр аның мөшк-ү ғә*бир*.

Мәне күрүб әйде кем: «сүзлә сүзүң,
*18а кәгазь* К*и*мәсе сынған кеше ирүр үзүң.

Йул сорарсән, буйлә үқ барғыл рәуан,
Бер йегет күргәйсән анда нагәһан.

Сән йулуңни сорғыл ул дәм үзедин,
Ни бойурса, чықма аның сүзедин».

Йөрүдем, бардым, йулуқтум үзенгә,
Чүн нәзар қылдым мөбарәк йөзенгә,

Қылур ирди ул йегет анда намаз,
Ул намазын төкәтеб қылды нийаз.

Мәне күрүб ул дәм әйде, хуш ишет:
*18б кәгазь* «Кем ирүрсән кәмәсе сынған йегет.

Йул сорарсән, йөрүгел, *йул билә* рәуан,
Сәңа бер пир отру килгәй бу зәман.

Сән сәлам қылыб аңа, сорғыл хәбәр,
Кем ирүр *(үзе) (...)* җәһанда р*аһи*бәр».

Йөрүдем, *и*лгәрү күрдүм үзени,
Кем намаз әйтеб сөртәр йөзени.

Барыб *и*лгәрү аңа қылдым сәлам,
*(...)* Сурәт *вә* мәғнәдә ирди ул тәмам.

Мәңа әйде: «Кәмәсе сынған кеше,
*19а кәгазь* Тотмағыл күңлү*ңен*дә йулың тәшвише.

Йул сорарсән, *сәңа* әйтәйем, орғыл қәдәм,
Раст йөрүгел буйлә уқ имди бу дәм».

Бу йегет әйде кем: «И пир*е* лятиф,
Бар*җ*ә мәғнә ичрә ирүрсән шәриф.

Теләкем улдур, мәңа қылсаң бәйан,
Мон*җ*ә төрлүк күргәнем эшни ғәйан.

Күб ғәҗаиб төрлүк эшләр күрдем уш,
Мәңа андин қыл хәбәр, и *(...)* пир*е* хуш».

Пир әйде: «Әйтәйем барчәсын сәңа,
*19б кәгазь* Бу дәм ичрә хуш қолақ тотғыл мәңа:

Ул сарай кем күрдүң аны ул зәман,
Ул шәһидләр қәсры ирүр, и җәуан.

Анда йатқан кешеләр ирүр шәһид,
Мең йыл ирүр йатқа*л*ы анлар, *ки* ишет.

Күргәнең атлығ кешедүр – Җәбраил,
Көн дә ике қурла килүр, аңлағыл.

Ул йегет кем күрдүң ул Илйас ирүр,
Кем үзе даим зийарәт*қ*а килүр.

Мәне сурсаң, Хөзер ирүрмән, и йегет,
*20а кәгазь* Уш сәңа қылдым хикайәт, хуш ишет.

Бер доға үгрәтәйем, йегет, сәңа,
Аны уқуб кер бу сағәт йулыңа.

Йомуб ачғунчә күзүңни сән рәуан,
Теләгән йиреңә *йитк*ел бу зәман».

Ул доғаны мән уқудым ирсә *укү*ш,
Күз йомуб ачғун*жҫ*ә килдем *и*үгә хуш.

## АЛТ*Ы*НЧЫ БАБ
## сабыр қылмақ сүзләрен бәйан қылур

*«Йа, әййуһа әл-ләзинә әмәну, әсбиру вә сабиру вә рабиту [вә әт-тәқу Аллаһә] ләғалләкүм түфлихүнә*[*]*»*

*20б кәгазь* Уш күңүл эчендин уқуб *бу* сәбақ, –
Сүзләри берлә бизәйем уш вәрәқ.

Җан вә дил берлә ишетеңез қәмуғ,
Шәрех итәйем аны, и кечек, олуғ.

Сабыр бабын қылайым сезгә бәйан,
Сабыр итеңез бар*җ*ә эшдә һәр зәман.

Сабыр қылмақ иргә ирүр хуш һөнәр,
Сабыр қылған кешени тәңре үгәр.

Тәңренең рәхмәтләре даим, ишет,
Сабыр қылғаннарға булур, и йегет.

*21а кәгазь* Бар*җ*ә тағәт башы, аңла, сабыр ирүр,
Сабыр қылған иргә Хәқ дә*в*ләт бирүр.

Дустлық ичрә сабыр қылсаң, и ғәзиз,
Қәтрә иркән булур ул *дәүләт* тәңиз.

Дошман үзә сабыр қылсаң йәнә үкүш,
Ғақибәт аны йеңәрсән, аңла хуш[**].

Сабыр берлә барчә эш хасил булур,
Сабыр қылған даимән ғақил булур.

---

[*] Коръәннең «Али Гыймран» сүрәсенең 200 нче аятеннән алынган бу гыйбарәдәге квадрат җәяләр эчендә бирелгән сүзләр кулъязмада юк.
[**] Бу бәйт белән аннан соңгысының урыннары алышкан.

*С*абир атлығ бер сәхабә, и йегет,
Сабыр ирди Хәқ йулунда, хуш ишет.

*21б кәгазь* Үзләри қылды риуайәт, тыңлаңыз,
Мостафаның хәзрәте*н*дин аңлаңыз:

«Сабыр берлә хасил итәр ир морад,
Сабыр берлә қайғу булур барчә шад».

Ул нәби*уллаһ* Йағқуб, хәзин,
Азрылыб күрмәде *(чөн)* Йусыф йөзен,

Дәрдә фөрқәт ичрә даим руз-у шәб,
Сабыр қылуб қылды Йусыфны таләб,

Ғақибәт табты аны ғиззәт билә,
Йөзени күрде аның дәүләт билә.

*22а кәгазь* Сабыр қылды ирсә Йағқуб – бер зәман
Булды Йусыф васлы берлә шад*и*ман.

Бер кем ирсә Мостафаны күрде ул,
Бәс имандин үзләренә сорди ул:

«Кем ни булур иман, айғыл, и рәсүл,
Ишетеб аны қылайым уш қәбул».

Мостафа бойурды аңа ул зәман,
Кем айа*т*ын, тыңла имди, и җәуан:

«Сабыр қылмақ ирүр иман, бел йәқин,
Хәқ йулында сабыр қыл, и әһле дин.

*22б кәгазь* Ул кешенең булур иманы тәмам,
Қайу кеше сабыр қылса ул *зәман**.

* Бу бәйт юлларының урыннары алышкан.

Сабыр қылмақ ирүр әүвәле а*җ*иғ,
Һич н*има* йуқ дөнйада андин қатиғ.

Соңы балдин сөчүк ирүр, и җәуан,
Сабыр берлә кү*җ*ай эш булур асан.

Сабыр қылған кешеләрни хасс-у ғам –
Бар*җ*ә ғаләм хәлқы сә*в*әрләр тәмам.

Бар*җ*ә эшдә сабыр қылғыл, и ғәзиз,
Сабыр сүзен аңла, и ғәқлы тәмиз*.

*23а кәгазь* Нәзым итәйем бер хикайәт имди уш,
Ишетеңез мәҗлес әһле бар*җ*ә хуш.

Кем Хорасан мөл*ек* ичрә бер мәлик
Бар ирди, тыңла, и гәнҗ билик.

Аты ирди *Б*усәғид, аңла аны,
Х*ө*км*е* берлә тотмыш ирди дөнйаны.

Бер вәзире бар иде аның мәгәр,
Ғилм-ү хикмәт ичрә ирди мөғтәбәр.

Аты ирде *Бүл*-Мөзаффәр үзенең,
Кем мотиғ*(...)* ирди ғалим*и* сүзенең.

*23б кәгазь* Падишаһ бер көн мәгәр үзе билә
Мәшғул ирди *ул* мәшүәрәт сүзе билә.

Итүке эчендә аның бер чайан
Тигәр ирди ул вәзирни һәр заман.

Нә*җ*ә тигәр ирди ғәқрәб үзени,
Кәсмә*с* ирди шаһ*(...)* берлә сүзени.

* Бу бәйттән соң тәнкыйди текстта булган «Хикайәт» сүзе язылмаган.

Сүзләйү торған сүзен йаңылмады,
Хале аның һич тәғйир булмады.

Шаһ берлә сүзлә*де* сүзләр*ене* хуш,
Сабыр қылыб зәхм*ене* кизлә*(...)*де *х*уш.

[...][*]

*24а кәгазь* Мәңа сез сүз әйтүр иркән ул зәман,
Тигте ирсә мәне ғәқрәб нагәһан,

Әйтә торған сүзеңез тыңлама*ди*н,
Ул бойурған эшеңез аңлама*ди*н,

Чықсам ирди ташқару, и шаһе җәһан,
Булғай ирди *эшем* бар*җә* зә*м*ан.

Ул ғәқрәб тиггәнигә түзмәдин,
Сезгә *мән* сабрым бар*ны* күргүзмәди*н*,

Бер тиггән зәхм*ин*гә ул дәм бақыб,
Китсәм ирди хәзрәтеңездин чықыб,

*24б кәгазь* Бәс сезнең дошманларыңыз *чәрки*гә,
Йаґ*(...)*ларыңыз қылычы зарбе*(...)*гә

Мән нәчүк түзгәй и*(...)*дем, шаһе җәһан,
Қол сезнең мән, сез белүрсез әл-әман».

Ул вәзир*(...)* сүзен*е* солтан тыңлады,
Ғақилан*е* сүзләгәнен аңлады.

* Бу урында кульъязманың бер кәгазе төшкән. Анда поэма текстындагы 395 нче бәйттән алып 404 нче бәйткә кадәрге өлеше язылган булган. 23б кәгазьдәге кустод: *шаһ*.

Шаһға хуш килди аның бу сүзләри,
Қылды инғам вәзир*(...)*гә үзләри.

Чөн аның ғақиллығыны белде ул,
Мәмләкәтни аңа т*иле*м қылды ул.

*25а кәгазь* Қайу кеше сабырлық булса үзе,
Ғақибәт табар морад*ин* бәс *(...)* үзе.

[...][*]

И вәфа иқлименең шаһи йәқин,
Кем вәфаңыз нуры*(...)*дин руйи зәмин.

Кичә-көндүз даимән рушән ирүр,
Йаз вә қыш ғаләм қәмуғ гөлшән ирүр.

Уш вәфа бабыны тәхрир итәйем,
Сүзләрени сезгә тәқрир итәйем.

Б*әс* вәфа ирүр, ишет, нуры җәһан,
Кем аның берлә *б*арур бу җисм-ү җан.

*25б кәгазь* Бел вәфа ирүр җәһан ичрә һөнәр,
Кем вәфа берлә булур ир мөғтәбәр.

М*ө*ғтәбәр булмақ теләсә һәр кеше,
Даимән булсун вәфа қылмақ эше.

Қай*у* ир кем сыйфаты булса вәфа,
Ул сәбәб берлә *күрәр* үкүш сафа.

Бу вәфа, аңла кем, өч төрлүк ирүр,
Кем вәфа қылса, сәламәт, хуш йөрүр.

[*] Бу урында тәнкыйди текстта һәм Уразай нөсхәсендә булган «Йэтенче баб. Вафа сүзләрен бәйан қылур» сүзләре язылмаган.

И *пәра*дәр, бер*(...)*е ирүр ғәһд эше,
Ғәһд қылса Хәқ йулында һәр кеше,

*26а кәгазь* Важиб ирүр қылмақ *(ул)* ғәһдиг*ә* вәфа,
Қылмаса күрәр қийамәтдә җәфа.

Бәс икенчесен айайын*ы*, тыңла уш,
Вәғдә қылса кешегә бер нәмә хуш,

Ул кеше күңлүн сафа қылмақ кәрәк,
Вәғдәсенгә хуш вәфа қылмақ кәрәк.

Вәғд*(...)*гә қылған вәфа булур кәрим,
Бу – хәдис мәғнәсе ирүр, и хәким.

Б*әс*, өченчесен айайын, тыңлаңыз,
Мәғнәсен*е* шәрех итәйем, аңлаңыз.

*26б кәгазь* Падишаһ *(...)* бик, вәзир*е* берлә қәмуғ,
Бер кем ирсә шарт қылса *(...)*, и олуғ,

Кем мәне *(...) ират*саңыз хуш күрүб,
М*и*н тәқи үлгүнчә табуғда торуб,

Көчүм йитәрчә сезгә хезмәт қылғаймән,
Сезгә даим мән һәуадар булғаймән.

Бу йусунлуғ вәғдәгә қылса вәфа,
Хезмәтендин китмәсә күрүб җәфа,

Ул кеше булур вәфадар, и йегет,
Уш вәфа әһле сүзе*(...)* йахшы ишет.

*27а кәгазь* Әйтәйем әсхабы кәһфнең қиссәсен,
Кем китәрүр ул күңүл*(...)* ғөссәсен.

Бер кү*җ*үк қылды чөн айларға вәфа,
Дөнйа вә ғоқбада табты ул сафа.

Чөн кем анларға ийәрде *бер* зәман,
Айақы ақсады йулда нагәһан.

Ничә кем қайтардылар, – ул қайтмады,
Күб йөр*е*де ақсаб, арыб йатмады.

Қылды ирсә ул вәфаны ихтийар,
Ля җәрәм булды вәлиләр берлә йар.

*27б кәгазь* Бәс вәфа берлә сафа хасил булур,
Ул сафа берлә сәғадәт табылур.

Ул сафа сөффәсенең шаһы тәмам,
Ул вәфа қөббәсенең маһы мөдәм,

Дин вә дөнйа, йер, күкнең *фәхери*,
Өнсе җан вә җен*(...)* пәйғамбәри:

Нәқел итәйем бер хәдис үзендин уш,
Төрк*и* теленчә мәғнәсен*е* аңла хуш.

Кем кәрим ул ирүр, аңла, и җәуан,
Вәғдәсенгә ул вәфа қылса рәуан,

*28а кәгазь* Вәғдәгә қылмақ вәфа ирүр кәрәм,
Бәс вәфа қыл вәғд*(...)*гә һәр дәмбәдәм*.

Ишетеңез бер хикайәт имди уш,
Бер мәхәллә бар ирди Бәғдадда хуш.

* Бу бәйттән соң тәнкыйди текстта булган «Әл-хикайәт» (яки Уразай нөсхәсендә булган «Хикайәт») сүзе язылмаган.

Ул мәхәллә әһле ирди бар*җ*ә бай,
Күрмәз ирди анда кеше һич гәдай.

Һәр к*ем* мөфлис булса ирди нагәһан,
Малларындин бирүр ирдиләр рәуан.

Қәйра *хәрам* қылур ирдиләр ани,
Булур ирди ул борунғы тик ғәни.

*28б кәгазь* Ул мәхәллә ичрә бер хужа мәгәр
Булды мөфлис нағәһан, ишет хәбәр.

Аты ирди Хамид Қоттан, *(...)* йегет,
Булды ирсә мөфлис үзе, хуш ишет.

Ул мәхәллә қәуме йыйғылыб қәмуғ,
Барды Шәмғун *ивү*нгә кечек-олуғ.

Шәмғун атлығ бер йәһүди ул заман,
Малы күб ирди, эшеткел, и җәуан.

Йыйғылыб қ*а*муғ үзенгә килдиләр,
Хамид Қоттан өч*ү*н сүзләдиләр.

*29а кәгазь* Әйделәр кем тәңрелық өч*ү*н аңа:
«Буру*җғ*а биргел *биш б*ең ақча, *сән безгә.*

Аның өч*ү*н бар*җ*әмыз йөк булалым,
Вәғдәси йетсә, әда без қылалым».

Шәмғун анлардин ойалыб ул зәман,
Бирәйем тиб вәғдә қылды нагәһан.

Күңле ичрә Шәмғун әйде кем бу көн
Вәғдә қылдым, бирәйем тәңре өч*ү*н.

Ул кичә йатты, ойуды, нагәһан
Йоқлайурда төшүндә *фә*хр*е* җәһан

*29б кәгазь* Әйде: «Аның хаҗәтен*е* қылд*ы*ң рәуа,
Без тәқи уш дәрденгә қылд*ы*қ дәуа».

Сорды Шәмғун: «Кем айа нуры җәһан,
Атыңызны әйтеңез мәңа рәуан.

Сезгә бер дәм, *анча*, бәндә булалым,
Н*и* бойурсаңыз – мән аны қылалым.

Йөзүңез нурын күрүб тынды җаным,
Сездин уқ ирүр – белүрмән-дәрманым».

Әйде: «Кем сорсаңыз мәне, Шәмғун, бу дәм
Сидық берлә дин йулына қуй қәдәм.

*30а кәгазь* Хәқ рәсүле мән, Мөхәммәд – атым уш,
Ғәрз ит*әл*ем сәңа иман имди хуш.

«Әшһәде әл ля иляһ*ә*» тиб рәуан
Айғыл: «илля-л-ляһ*и*» сүзен*(...)*, и җәуан».

Шәмғун әйде: «Хәқ рәсүле Мостафа,
Күңлүм ичрә тулды уш сүздин сафа.

Тәңре*не* бер*(...)*сени белдем, Хәқ рәсүл,
Қылдым ислам динени бу дәм қәбул».

Җан вә дил берлә булуб ул мөселман,
Дөнйа вә ғоқбада табты хуш *а*ман.

*30б кәгазь* Дөнйа биреб ахирәтни алды ул,
Даимән дә*в*ләт эчендә қалды ул.



دنیا بر بیبه آخر تا لی آلدی اول

دایما دولت ایچنده قالدی اول

سکسننچی باب صدیق سوزلارنی بیان قیلور

قال الله تعالی و مصدقا لما بین یدیه

ای جهان عاشقلارنینک صادقی

ای لامکان صدیقلارنینک عاشقی

عشق برلا صدق سوزنی تنکلانکز

تقریر ایتاین ای خوش انکلانکز

صدق بابینی قلایم سزکا بیان

اول بیان برلا آنی کورونکز عیان

شعر کی نالنه

*«Нуры содур» поэмасының Ижевск нөсхәсе. 30б кәгазь.*

## СӘКЕЗЕНЧЕ БАБ
## сидыкъ сүзләрен*е* бәйан кылур

*Қалә Аллаһы Тәгалә: «Вә мусаддиқән лима бәйнә йәдәйһи»*

И җәһан ғашиқларының садиқы,
И заман с*ид*диқларының ғашиқы.

Ғишық берлә сидық сүзен тыңлаңыз,
Тәқрир итәйе*н* аны – хуш аңлаңыз.

Сидық бабын қылайым сезгә бәйан,
Ул бәйан берлә аны күрүң гәйан.

*31а кәгазь* Төрки* теленчә сидық мәгънәсен белең*ез* –
Күнилек берлә һәмишә эш қылың*ыз*.

Сидық, йәғни күни сүзләмәк булур,
Күни сүзләгән кеше дә*в*ләт булур.

Қайу кеше теләсә дә*в*ләт тәмам,
Күни булсун сүзләре аның мөдам.

Күнүлүк берлә тәбар дә*в*ләт *тәмам* қәмуғ,
Күни сүз берлә булур кечек олуғ**.

Кем олуғл*уг* теләсә даим*ә*н үзе,
Барчә берлә хуш, күни булсун сүзе.

*31б кәгазь* Күниләрни барчә ил-улус*(...)* сә*в*әр,
Күни сүзләгән кешени Хәқ үгәр.

---

* Бу сүз 30б кәгазьдәге кустодта «төрки» дип, ә 31а кәгазьдә «төрк» рәвешендә язылган.

** Ш.Абилов басмасында «кечек-олуг» дип ике сүз арасына сызыкча ялгыш куелган. Чөнки монда автор «кечек» кешенең «күни сүз берлә» олуг булуын күздә тоткан дип уйлыйбыз.

Адәм уғлының *үч*үде ичр[ә] бел:
Бер тылсым бу әл-ғәҗәб ирүр бу тел.

Кем җәһан эчендә, и дин олуғ*(...)*,
Гәнҗ, дәвләт, рәнҗ *вә* михнәт-қамуғ*(...)*

Ул тылсым ачқучы берлә ачылур,
Нә к*ем* телдин чықты – ул башқа килүр.

Тел күни булса, күнүлүр *ил*, азақ,
Күни булур барчәсы бу күз, қолақ.

*32а кәгазь* Игри булса тел, – қәмуғы игелүр
Ул сәбәбдин абруйы түгелүр.

Бер хәдиснең мәғнәсени қәйра уш
Тәрҗемә қылайым имди, тыңла хуш.

Ул – нәбүвәт мәғдәненең җәүһәри,
Ул – рисаләт тэңизенең гәүһәри.

Сахибе миғраҗ садрел-әнбийа,
Фәхри ғаләм Хәқ рәсүле *вә* Мостафа.

Ул мөбарәк ләфзыдин *имди* үзе,
Ишетеңез бу ирүр айған сүзе. –

*32б кәгазь* Нәзым берлә әйтәйем сезгә аны,
Ғәиб қылмаңыз бу сүздә сез мәне.

Адәм уғлы уйғаныб торса рәуан
Сабах йатған йерендин нагәһан,

Телгә әйтүр бу қәмуғ әндамләри,
Хал тел*(...)* берлә ишеткел һәрбери:

Кем ирүрсән безгә, и тел, сән олуғ,
Сән төзәтсәң, без төзәнүрмез қәмуғ.

Игри булсаң, сән төзәлмә*(...)*дин, и тел,
Бар*ы*мыз игри булурмыз, – аны бел.

Бәс, ни килсә баш*ға*, бел, телдин килүр,
Адәмиға н*и* к*ем* қылса, тел қылур.

*33а кәгазь* Кеше йал*ла*ған сүз билә та*б*маз нәҗат,
Туғры сүз берлә тәбар даим хәйат.

## *ӘЛ-ХИКАЙӘТ*

Бер хикайәт тыңла имди, и олуғ,
Сүзләрени нәзым қылайым қәмуғ.

Бер зәман эчендә бар ирди мәгәр
Бер солтан, ишетеңез бу*дур* хәбәр:

Уғлы хален қылды анларға бәйан,
Фикер қылды бик, вәзирләр ул зәман.

Әйделәр кем таң*л*а а*в*ға чығалым,
*33б кәгазь* Шайәд а*в*да сүзләгәй ул – бәқалем.

Таң берлә атланды а*в*ға хасс-у ғам,
Йөрүр ирди *ав* а*в*лайу барчә тәмам.

Шаһзадә лаласы берлә мәгәр
Йөрүр ирди *халық*, *и*шет бу хәбәр:

Очар ирди нагәһан бер *ничә* қаз,
Хуш һауа йөзендә қылдылар а*в*аз.


33

کشی بیللغان سوزن بیلا تا بمازنجات

توغری سوزلا بر لا تاپار ادایم حیات

الحکایت

بر حکایت تینکلا ایمدی ای اوغول

سوزلارینی نظم قلایم قموغ

بر زمان اچنده بار ایردی حکم

بر سلطان اشتنکز بو دور خبر

اوغلی حالین قیلدی آنلارغه بیان

نکر قیلدی بیک و ویس للار اول زمان

ایدیلار کیم تانکلا آقزغا چقالیم

*«Нуры содур» поэмасының Ижевск нөсхәсе. 33а кәгазь.*

Лала салды қарчықасын ул зәман,
Қазны *тотты* қарчықасы, и җәуан.

Шаһзадә әйде ул сағәт, ишет,
*34а кәгазь* Бу хәдис мәғнәсени аңла, йегет:

Һәр ки тот*ты* тел*е*не – қотулды ул,
Тел*е*не тотмаған уш тотулды ул.

Чөн ишет[т]е ирсә лаласы рәуан,
Шаһ сәвүнече тәйү барды ул зәман.

Шаһ сәвүнүб бәрде хәлғәтләр аңа,
Әйде кем: «Шаһзадәни килтүр мәңа».

Килде ирсә шаһзадә*(...)* үзенгә,
Монтазир ирди шаһ аның сүзенгә.

Ни*җ*ә кем шаһ лот*ыф* итеб сорды *с*үзен,
*34б кәгазь* Шаһзадә сүзләмәде һ*иҗ* сүзен.

Шаһ қылды лаланы ул дәм таләб,
Хәшем берлә қылды аңа ул ғазәб:

«Кем мәңа йалған хәбәр килтүрд*е*ң уш,
Булдуң имди мөстәхәқ үлмәгә хуш.

Үлтүрүңез тиб бойурды шаһ ани»,
Шаһзадә қәйрә әйде сүзени:

«Һәр к*ем* тотты телени – қотулды ул,
Телни тотмаған уш тотулды ул».

Ишетеб уғлы сүзен шаһ булды шад,
*35а кәгазь* Ул мескин лаланы қылды азад.

Шаһ әйде лотф берлә уғлына:
«Кем бу*лган* сер*(...)*ең*не* айғыл сән мәңа.

Ни сәбәбдин сүзләмәдең, и уғул,
Мәне қылдың ошбула*й* зар-у мәлул.

Тәңре хақы ө*җ*үн айғыл сән мәңа,
Аймаз ирсәң, хатерем қалур сәңа».

Шаһзадә әйде: «И шаһи җәһан,
Бер хәдис үгрәндем ирди ул зәман.

*(Мәңа)* остадым бетиб бирде *(ани)*,
*35б кәгазь* Ошбу ирди әйтә*л*ем мәғнәс*ени*:

Һәр к*ем* тотты телни – қотулды ул,
Телни тотмаған уш тотулды ул.

Күңлүм ичрә әйдем, и шаһи җәһан,
Бу хәдисни сынайын мән бер ғәйан.

Раст булса, мәғнәсени сынайын,
Мән хәқиқәт бил*е*б аны, тынайын.

Ул сәбәбдин сүзләмәдем бер зәман,
Ғәфу қылғыл мәндин, әй*а* шаһи җәһан.

Шәрх итәйем сезгә ғаләм солтаны,
*36а кәгазь* Раст ирүр сынадым ирсә мән аны:

Тотса ирди телени сахрада қаз,
Тотмаз ирди ул дәм ичрә аны *й*аз.

Тотса ирди лала ул дәм телени,
Үлмәгәмү бойурур ирдеңез ани.

Күни ир*де* бу хәдис, сынадым уш,
Төрки теленчә бу ирүр мәгънәсе хуш:

Һәр к*ем* тотты телени, қотулды ул,
Телени тотмаған уш тотулды ул».

## ТУҚУЗЫНЧЫ БАБ

[...][*]

*36б кәгазь* Сал қолақ самитлық ичрә *бу* ж*иһ*ан,
Һәр к*ем* самитдур ирүр *(ул)* пәһлуан.

Күб ирүр бу самитлық*(…)* файдасы,
Тыңла имди, күбдүр бу *и*шнең файдасы.

Әйде, самит булуң*ыз* тиб, ул Мостафа:
«Мән сәк*кәт* сәлл*ә*м вә мән сәм*м*әтә нә*ч*а».

Һәр ки сакиндур сәламәт булғай ул,
Самит улған һәм нәҗатқа табғай йул.

Һәр, ки салимдур *нур ирүр* даим *й*ө*з*и,
Мөхкәм *вә* мөстәхкәм булур аның сүзи.

*37а кәгазь* Кем бу самит сүзедин, шаһи җәһан,
Қылайым имди с*ез*гә тел дәр*бә*й*а*н.

### Ә*Л*-ХИКАЙӘТ

Бар ирди К*о*нну*х*да бер пир ник-ү хаһ,
Килүрдин вә*қ*и*ф* вә кичмешдин агяһ.

[*] Бу урында тәнкыйди текстта һәм Уразай нөсхәсендә булган «самит қылмақ сүзләрен бәйан қылур» дигән сүзләр язылмаган.

Үзе назүк иде *вә* күңле кәрим,
Ил ичрә ирди ғалим һәм хәким.

Ултуруб м*и*нбәр үзә *да*им үзи,
Тәңре әмре иде сүзләгән сүзи.

Бер көн үзе вәғәз эчендә нагәһан
Кем телендә йөрүде бу сүз рәуан:

*37б кәгазь* «Һәр ки самит булса һәр *и*шдә үз*и*,
Кергәй ул дарес-сәлам ичрә үз*и*».

Тыңла имди бу хикайәтни тәмам,
Аңла имди бу сүзүмни ник-ү нам.

Бар и*(...)*ди мәҗлес эчрә бер җәуан,
Ошбу вәғәзне күңл*ендә* тот*т*ы нағәһан.

Кем ул *ил* ичрә булур*де* үз*и*, –
Мәшһүр ирди самитлық эчрә сүз*и*.

Бер йәһүди қоң*ы*шл*ы*қда бар и*(...)*ди,
Үзе бәдбәхт-ү йаман *ин*кяр иде.

*38а кәгазь* Ултурур*де (...)* бер көн самит җәуан,
Килди, азар итди ул бәдбәхт, йаман.

Ошбу Самит пәһлуан назир иде,
Ул йәһүд*и* қәтле*нә бә*с қадир иде.

Самит итеб өн*д*әмәде һич сүзи,
Күңл*е*нә ағыр алыб, чатмады йөзи.

Йоқлайурда ул кичә Самит җәуан,
Керде төшенә аның шаһи җәһан.

Әйде аңа: «Ишет сән, *(...)* нәу җәуан,
Кем ирд*е*ң самитлық ичрә пәһлуан.

*38б кәгазь* Кем хәбәр қылды мәңа *ул* Җәбраил,
Йарлықадым тэйү сәни ул җәлил».

Йәнә әйде, ишетең, ул фәхр*е* җәһан:
«Сэкез уҗмах кем сәңа булды мәкян».

Кем бу сүздин шад булдым *(...)* үз*е*мә,
Кем күр*е*нмә*с* булды *(...)* шаһ күз*е*мә.

Уйғаныб, возу итеб вақт*ғ*а бәқар,
Нагәһан берәгү уш иш*ү*к қақар.

Торды, бақты, күрде: ул – *йә*һүд ирүр,
Әйде: «*И* самит, мәңа иман үгрәт тэйүр:

*39а кәгазь* Кем мөселман бул*(...)*ам имди бу зәман,
Таб*ғ*ай мән аның илә утдин *а*ман.

Динеңез хәқлықыны күрд*е* күзем,
Ошбу дин*(...)* хәқлықына йуқ*дур* сүзем.

Йатыб уш *(...)* йоқлайурда нагәһан
Кем күр*е*нде күзүмә анд*а* җәһан:

Олуғ, кечек – барчә килмешләр қәмуғ,
Кем йәнаша тезелмеш йэти тәмуғ.

Тотубән мәне анда килтүрдиләр,
Самитны азар иткән бу тэйдиләр.

*39б кәгазь* Фәрман қылды: «Ишет сән, *йарлықа*,
Атың аны, тиделәр тәмуғ утиға».

Қурқуғумдин *сискәнүбән т*ордым уш,
Ул сағәт Хәқ*ғ*а иман килтүрдем уш.

Барчә малын Хәқ йул*ы*нда қылды сарф,
Мундин артуқ *йи*тмәде һич *(...)* хөр*у*ф.

[...][*]

Ғәфу бостанының, и тазә гөле,
Қаршуңызда сайра*р* уш тел былбылы,

Ғәфу бабын имди хуш рушән итәр,
Сүзләр*не* күң*лүнә* гөлшән итәр.

*40а кәгазь* Ғәфу қылмақ ирүр ирнең ирдәме,
Ирдәмендә мең дәм ирүр бер дәме.

Ғәфу қылмақ тәңре бойруқы ирүр,
Бойруқын тотқанға ул җәннәт бирүр.

Хәқ тәғалә б*о*йруқыны тот рәуан,
Хасс-у ғамдин ғафу қылғыл, и җәуан.

Кем йаманлық қылса сезгә дәмбәдәм,
Сез аңа ихсан билә қылың кәрәм.

Ғәфу қылмақ берлә булур ир ғәзиз,
Ғәфу қыл барчәдин, и ғәқлы тәмиз[**].

*40б кәгазь* Ғафу *ти*мәк ни тимәк булур ишет,
Мәғнәсени әйтәйем, аңла, йегет.

---

[*] Бу урында тәнкыйди текстта булган «Баб унунчи. Ғәфу қылмақ сүзләрен бәйан қылур» дигән сүзләр язылмаган.
[**] Бу бәйт Ш.Абилов басмасында дүрт бәйткә өстәрәк.

Кем кичүрмәк ирүр бер *(...)* бәндәдин,
Азған вә йазған бәси шәрмәнд*әд*ин,

Хәқ әйтүр рәхмәт қылыб анларға *(...)* уш:
«Рузи қылдуқ җәннәт фирдәүсни *х*уш».

Хури ризуан теләгән кеше мөдам
Ғәфу қылсун барчәлардин ул тәмам.

Нагәһан йазыб йаңылса бер кеше,
Кичүрүб андин кәрәм булсун эше.

*41а кәгазь*

## ӘЛ-ХИКАЙӘТ

Бер хикайәт нәзым ит*әл*ем, аңлаңыз,
Җан вә дил берлә сүзени тыңлаңыз.

Кем озаға рузгяр ичрә мәгәр,
Бер мәлик бар ирди әср-ү мөғтәбәр.

Кем аты Мәсғуд иде үзенең,
Шаһы ирди үзе ул йир йөзенең.

Үзләри ғәсри эчендә, и йегет,
Һәм йәнә бер шаһ бар ирди, хуш ишет.

(Ибн*е* *Әшғәс*) ирди ул шаһ *(аты)*, бел,
*41б кәгазь* Уш хикайәт қылсун аны сезгә тел.

Бу икәгү дошмән ирдиләр тәмам,
Алдар ирди бер*(...)* берени мөдам.

Табмас ирди бере беренгә зафәр,
Тыңла имди, итәйем уш мән хәбәр.

Ғақибәт Мәсғуд йығды ләшкәрен,
Ил-улусда қуймады ор*ы*ш ирен.

*Қәссе қәүмләр* икәгү тор*ы*штилар,
Ике ләшкәр күб қатығ орушт<ins></ins>илар.

Тәңре тәқдир[е] берлә нагәһан *(...)* –
*42а кәгазь* Ибн*е Әшғәс* ләшкәрени қырды *рәүван*.

Хәқ тәғалә бирди *җ*өн Мәсғудға йул,
Ибне Әшғас ләшкәрени қырды ул.

Алдылар әсрү күб улҗа *и әмир*,
Ул *җи*рикдин қылдылар үкүш әс*ир*.

Ғизз-у носрәт берлә *ив*гә килди шаһ,
Ул әсирләрнең қәмуғын*ы* йығди шаһ.

Үзе алтун сандәлида ултуруб,
Сорар ирди бар*җ*ә бер-бер килтүрүб.

Бер йегеткә төште нагәһан күзи,
Аны ул дәм килтүрүб сорды үзи.

Ул йегет әйде *кем*: «И шаһи җәһан,
*42б кәгазь* Бер сүзүм бар – әйтәйем, биргел *а*ман».

Шаһ әйде кем *а*ман бирдем *(...)* сәңа,
Ни сүз*е*ң бар ирсә, айғыл уш мәңа».

Ул йегет әйде кем: «И шаһи кәрәм,
Сүзүм әйтәйем, ишеткел ошбу дәм.

*Бәс* теләгән эшни бирди Хәқ сәңа,
Хәқ теләгән эшни қылғыл сән *мә*ңа.

Носрәт ирди теләгең, – таб*т*ың аны,
Ғәфу ирүр сәндин *уш* теләгәне.

Хәқ тәғалә сәңа дә*в*ләт бирди уш,
*43а кәгазь* Дошманыңны қәһр қылды бар*җә* хуш.

Сән тәқи Хәқлық ө*җү*н, шаһи җәһан,
Ғәфу итеб бездин кичүргел бу зәман.

Сән безем йаманымызға бақмағыл,
Қәһр уты берлә безни йақмағыл.

Лотф қылды *(уш)* сәңа пәрүәрдигяр,
Қәһр қылма безгә сән, и нам*и*дар.

Ғәфу итеб қыл күңлүмезни имди шад,
Лотф қылыб бар*җа*мызни қыл азад.

Кем *изе*мдин даимән килүр кәрәм,
*43б кәгазь* Бәс кәрәм қыл безгә, *(...)* шаһ*а*, сән бу дәм».

Шаһ ул дәм аңлады йегет сүзен,
Күрүкле сүз әйтүр тэйү үгде үзен.

Қылды айған сүзләрен ул дәм қәбул,
Ул йегетнең қылмады күңл*е*н мәлул.

Ул йегет сүзени ул дәм ишетеб,
Ул әсирләрни *и*сиргәб рәх*и*м итеб,

Хәқ ризасы ө*җү*н ул шаһи җәһан
Бар*җа*сын*(...)* азад қылды ул зәман.

Ул йегетни йарлықаб суйурғады,
*44а кәгазь* Ғомре барын*җа* тыныб хуш ырғады.

604a *Бу китаб хан доғасы берлә тәмам,*
*Қилғанын бәйан қилур кем мөдам.*

И җәһан солтанларының солтаны,
Йэти иқлимда қәмуғ ханлар ханы,

Дөнйаны тултурд*у*ңыз *и*ман-*ү* *а*ман,
Булды рахәт ичрә бар*җ*ә җисм-ү җан.

Булд*ы*ңыз бу көн *а*манға сез сәбәб,
Кем ирүрсез дөнйа ичрә зилли рабб.

*(...)* Сайәңезгә *бүкүн сәфир* килгән кеши,
*44б кәгазь* Ғәдлеңез берлә *тәбар* барч*а* эши.

Сезгә йари қылды ирсә *й*ар*(...)*ыңыз,
Уш сағәдәт булды даим йарыңыз.

Ни уйун кем уйнадылар, от*дыңу*з,
Ғақибәт дөнйаны барчә то[т]т*ыңу*з.

Мәшриқ-у мәғриб сезнең булды тәмам,
Падишаһлар булды уш сезгә ғолам.

Уш мөсәлләм булды сезгә бу җәһан,
Хуш мөсәххәр булды бар*җа* өнс-*ү* җан.

Хөкмеңез дөнйаны бар*җ*ә тотты уш,
*45а кәгазь* Ғәдлеңез*(...)* тулды җәһан*да* имди хуш.

Күрсә ирди ғәдлеңезни Нәүширван,
Булғай ирди бәндәңез, шаһи җәһан.

Хат*и*м Тай вөҗүдеңез йөзен күрүб,
Хиҗләт ичрә қалғай ирди ултуруб.

Ул қәтығ *б*адин уқ атсаңыз *йә*саб,
Бәндә булғай Рөстәм-ү *Афрүа*с*(...)*аб.

Уш җәһандағы мөбаризлар қәмуғ
Қолуңыз булуб қылур сезгә т*әб*уғ.

Тәңренең лотфы ирүр шаһ үз*е*ңез,
*45б кәгазь* Кем ирүр дөнйа*гә* б*ой*руқ сүз*е*ңез.

Хөкмеңез берлә төзә*л*де ил-улус,
Сүз*е*ңез берлә туланды ғәқил-ус.

Дә*в*ләт *вә* фәт*(...)*х-*ү* зафәр берлә мөдам,
С*о*лтанәт тәхт*(...)* үзә йөз йыл тәмам.

Ғизз-у дә*в*ләт берлә, *(...)* шаһ, йәшәңез,
Қайда булса дошманыңыз, – түшәңез.

Сезгә кем қылса доғалар дәмбәдәм,
Лотф бе*(...)*лә қыл*ы*ңыз аңа кәрәм.

Ғәрш изеси *йа илаһ*ел-ғаләмин,
*46а кәгазь* Бу доғаны мөстәҗаб иткел, *а*мин.

Бер сүзүм бар – аны тәхрир итәйем,
Мә*г*судымны сезгә тәқрир итәйем.

Шаһи ғаләмнең мөбарәк атына
К*үб дога* булсун тиб арығ затына,

Төрки нәзым итеб бет*ү*д*ү*м *бу* китаб,
«Нуры содур» аның атыны атаб.

Хәтем қылдым сүзләрени имди уш,
Хәқ мөбарәк қылсун аны шаһға хуш.

Ни*җа* кем булса җәһанда – *ай вә йыл*,
*46б кәгазь* Ни*җа* кем сүзлә*нсә телдә* қал-у қил,

Һәркем аны уқыса һәр дәмбәдәм,
Йа қа*җ*ан кем бет*е*са аны қәләм,

Падишаһға даимән қылғай доға,
Җан вә дил берлә үкүш айғай сәна.

И доғаларны ишеткән пак-ү тәк,
Хәзрәтеңдә уш қылыб *й*үзүм *бүхак*,

Зари берлә м*и*н *(доға)* қылайым уш,
Лотф берлә иҗабәт қыл аны хуш.

Бу зәман ғазиларының солтаны,
*47а кәгазь* Дөнйа ичрә барчә ханларның ханы;

Шаһи ғаләм ғөмрени қылғыл үкүш,
Йэти иқлимни аңа биргел өлүш.

Дәвләтени қыл җәһанда мөстәдам,
Ғиззәтени қыл зийадә собх-у шам.

Носрәт-ү фәтх, зафәр берлә ани
Қыл сәғадәт ичрә даим, и ғәни.

Бу китабны қыл мөбарәк сән аңа,
Йарлықаб қылғ*ай* ғинайәт уш мәңа.

И караңғу төнни айдын қылғучи,
*47б кәгазь* И йазуқлар дәфтәрени йуйғучи,

Ғ*аффир*-у ғ*аффар(...)* ирүрсән *и* ғәфур,
Мәғфирәт җамыни мәңа син эчүр.

Сәңа лаиқ қылмадым һәргиз ғәмәл,
*И*шләрем қәмуғ *зәға*, *вә һәм зәғ*ил.

*640а Ғәфу қыл йазықларымны и ғәфур,*
*Йаратқаным, тағәтемне қыл қәбул.*

Дөнйада қылдым үкүш фисқ-у фәсад,
Рәхмәтеңгә қылдым, и Хәқ, иғтимад.

Ғәрқ ирүр мән мәғсийәт ичрә мөдам,
*48а кәгазь* Булды ғисйан берлә *у*ш ғөмрем тәмам.

Тәүбә қылд*ы*м, бар*җа* йазуқдин кичеб,
Сән иҗабәт қылғыл имди, *и* мө*ч*иб.

Ғәфу қылыб сән йазуқларым кичүр,
Лотф берлә қәһрең утыны о*җ*ур.

Кем ғазәбдин рәхмәтең сабиқ ирүр,
Йарлықамақ сәңа уқ лаиқ ирүр.

[...][*]

Йарлықар*сың* булса*(...)*, м*и*нем тәк сад һәзар,
Рәхмәтеңнең тиңезендин ни қ*у*лар.

Рәхмәтең дәрйасы ирүр *би* гиран,
*48б кәгазь* Йарлықанур қәтрәсе*(…)*дин өнсе җан,

Күб ғәмәл қылмақ берлә һәрбер кеши
Җәһд қылса дөнйада йаз вә қыши,

Булмағ*а*нчә тәңрене*ң*, лотф*(…)* аңа –
Кермәгәй җәннәткә, қолақ тот моңа.

---

[*] Бу урында бер бәйт язылмаган.


یارلیقاندر قطمرا ایسدین الناس و جان
کوب عمل قیلماق برلا هم بر کشی
جهد قیلسه دنیاده یادو قیتیشی
بولماغنچه تنکری ینک لطف آنکا
کیرماکای جنت کا قولاق توت مونکا

حکایت

بر حکایت علایم انکا بو دم
صاوقانده خوش ایشت فخر الامم
جابر انصاری ایتور ای جلدلر
ایدی منکا حق رسولی اول زمان
کم

*«Нуры содур» поэмасының Ижевск нөсхәсе. 48б кәгазь.*

# ХИКАЙӘТ

Бер хикайәт қылайым, аңла бу дәм,
Садиқанә *хуш ишет* фәхрел-өмәм.

Җабир Ансари әйтүр, и җәуан,
Әйде мәңа хәқ рәсүле ул зәман:

*49а кәгазь* Кем қатымдин хали чықти Җәбраил,
Ул хикайәт мәңа қылды – аңлағыл.

Кем бәни Исраил ичрә мәгәр,
Бер Заһид бар иде хуш мөғтәбәр.

Хәқ йулунда кү*к* оруғ*(...)*дин ки*се*леб,
Ғөзләт ит[т]е бер җәзирәдә килеб.

Ул җәзирә тэңиз ичрә ирди, бел,
Бөтмеш ирди анда бер тағ, аңлағыл.

Чықар ирди ул тағ*(...)ди*н бер булақ,
Ақар ирди сувы балдин татлы*(...)*рақ.

*49б кәгазь* Ул булақ өст*е*ндә бөтмеш бер тирәк,
Сайәсе бағ *вә* Ирәмдин йахшырақ.

Нар *ағаҗ*ы ирди ул тирәк, *и*шет,
Көн дә бер нар бирүр ирди, и йегет.

Заһид ул йирне күрүб қылды мәқам,
Тағәт итде анда даим собх-у шам.

Һәр сәб*а*х ул чәш*ем(...)*гә килүр иде,
Абдәст алыб ул намаз қылур иде.

Ул нар берлә уружы*(...)*ны ачыб,
Һәр кэчә *ул* чәшмә с*ы*в*ы*ндин эчеб,

*50а кәгазь* Иртә-кэчә қылыб ул Хәққа нийаз,
Таңға тигрү қылур ирди күб намаз.

Көндүз уруж тотуб ул Заһид мөдам,
Кичә тағәт берлә биш йөз йыл тәмам[*],

Ғөмре ахир булды ирсә, нагәһан,
Лотф қылды Хәқ аңа, ишет, җәуан.

Сәждә эчрә *қылды* җаныни тәслим итеб,
Ахирәтғә барды дөнйадин китеб.

Чөн қийамәт көне булғанда рәуан
Хәшр булса бу хәлаиқ би гөман,

*50б кәгазь* Хәқ тәғалә қылғай *ул* Заһидкә хитаб:
«Рәхмәтем берлә сәни м*и*н йарлықаб,

Бирәйем *(...)* сәңа бәһишт*и* җауидан,
Кем тәмуғдин таб*қ*ул имди хуш *а*ман».

Заһид айғай: «И кәрим *(...)* би нийаз,
Мончә йыллар қылғаным рузә, намаз

Кайда барди, мәңа белдүргел ан*и*,
Йарлықар сән рәхмәтең берлә*н* мән*и*».

Хәқ тәғалә айғай: «И Заһид, фозул,
Рәхмәтемни қылмадыңму сән қәбул.

*51а кәгазь* Мән хисаб итәйем уш сәнең билә,
Йахшы аңла бар*җәсе*н, фик*рәт* қил*а*.

---

[*] Бу бәйт юлларының урыннары алышкан.

Йуқдин *бән* бар әйләдем, Заһид, *(...)* сәни,
*Кем* сәнең аслың бер қәтрә мор*д*ар мәни.

Хар с*ы*вудин сәни мән қылдым ғәзиз,
Сәңа бирдем сиххәт вә ғәқли тәмиз.

Баш, айақ һәм күз, қолақ бирдем сәңа,
Сән намазың миннәт итәрсән мәңа.

Йити әғзаң төз йараттым мән қәмуғ,
Кем аның берлә мәңа қылдың тә*б*уғ.

*51б кәгазь* Ул ғибәдәт қылмаға тәүфиқ йәнә
Рузи қылдым, и фозул Заһид, сәңа».

*Бу* һәйбәт*(...)*дин *исе киткәй ул зәман,*
З[а]һид мескин сусаға*й* нагәһан.

Бер фәрештә сахибе хөсн*е* җәмал,
Бер қәдәхни тултуруб абе зөлал,

Заһид а*ләте*дин рәуан кичкәй килеб,
Айғай ул Заһид аңа зари қылыб:

«Кем су*в*са*ғ*лықдин йөдәдем *әсри* уш,
Мәңа бир*гел*, эчәйем ул сувны хуш».

*52а кәгазь* Ул фәрештә айғай: (И) Заһид, мәңа
Тағәтең биргел, бирәйен сув сәңа.

Заһид айғай: «*(…)* йөз йыллық тағәтем
Бирәйем кем, йуқтур үзгә тақәтем».

Ул фәрештә қылмағай аны қәбул,
Йадағай Заһид булуб ул дәм мәлул.

Ғақибәт Заһид су*(…)*са*г*лық*(…)*дин й*ө*дәб,
Бар*җә* қылған тағәт*не* аңа атаб,

Киткәй үзе *(...)* дөнйадин тилмүрүб,
Тағәтен*е* бер эчем сувға *табшуруб*[*].

*52б кәгазь* Ул *җ*әдәхни алыб эчкәй ул зәман,
Тағәтендин би нәуа қалғай һәман.

Қылғай ул дәм хә*с*рәт-*ү* ғиззәт *г*итаб,
Кем, айа, Заһид, мәңа айғыл җәуаб:

690 «Биш йөз йыл тағәт иткәнең қәмуғ
Бер эчем сувға сатыб, қалд*ы*ң қор*ы*ғ.

Баруб имди тәмуғғә кергел рәуан».
Зари қылыб, Заһид айғай ул заман:

«Барчәны йуқдин йаратқан пак-ү тәк,
Белдем үзүмни, м*и*не қылма һәлак.

*53а кәгазь* Кит[т]и *г*өмр*ү*м ичрә қылған тағәтем,
Тәмуғ ичрә йанмаға йуқ тақәтем.

Кем йарат[т]ың м*и*не син әср-ү зәғиф,
Лотф қылғыл мәңа *бер* көн, и ләтиф.

695 Рәхмәтең берлә м*и*не с*и*н йарлықа,
Рузи қыл лотфың бе*(...)*лә мәңа лиқа.

Лотф*(...)* берлә қылмасаң мәңа нәзар,
Булды эшләрем қәмуғ*(...)* зир-*ү* зәбәр».

Хәқ тәғалә айғай: «И Заһид, бу дәм
Рәхмәтем берлә сәңа қылдым кәрәм.

---

[*] Бу бәйт белән аннан соңгысының урыннары алышкан.

*53б кәгазь* Барғыл уш җәннәткә имди би гөман,
Рузи қылдым сәңа хуш хури җинан.

Қыл тәнәғғем анда күб ниғмәт билә,
Йарлықадым сәни мән р*а*хмәт билә».

Йа иляһел-ғаләмин, имди бу дәм
Тәүбә қылыб бар*җ*әмыз қылдуқ нәдәм.

Хәзрәтеңдин теләнү килдүк қәмуғ,
Рәхмәтеңдин безни қайтарма қоруғ,

Кем ирүрмез тағәтеңдин бинәуа
Лотф берлә безгә қыл рәхмәт ғәта.

[...][*]

*54а кәгазь* Дәвләт эчендә йашәңез күб зәман.

Атыңызға нәзым қылғаным китаб
Хәтем қылдым, аны мән төрки й*ә*саб.

Тигмә бер бәйти ирүр берендин хуш,
Сүзләри в*а*ғәз-нәсыйхәт ирүр уш.

Уқыған ғақил кешеләр аңлағай,
Бу зәғифә бичарә қол*(...)*н*ы* таңлағай.

Тигмә йирдин җәм*и*ғ қылыб сүзләрен,
Мона күргүздүм мәғ*(...)*нә йүзләрен.

Тәржем*а* қылыб пар*җа*сы телен, *и*шет,
*54б кәгазь* Нәзым қылдым төрки теленчә, йегет.

[*] Бу урында кулъязманың бер кәгазе төшкән. Анда поэма текстындагы 703 нче бәйттән алып 712 нче бәйткә кадәрге өлеше язылган булган. 53б кәгазьдәге кустод: *рәхмәтең.*

Йил т*и*к исеб кичәсә *уш* рузгяр,
Дөнйада қалғай бу[*] сүзләр йадгяр.

Кем уқур булса аны пир-ү җәуан,
Теләгем улдур үзендин ул зәман:

Ханға қылғай даимән үгүш доға,
Мәғнә аңлаб, табса *ул* сүздин сафа.

Хан доғасы йөр*(...)*гәй телләр үзә,
Важиб ирүр д*ө*нйада илләр үзә.

Кем һәмишә ханға қылғайлар доға,
*55а кәгазь* Төн*(...)* көн*(...)* айғай қәмуғлар*ы* сәна[**].

Ничә кем булса җәһанда бу китаб,
Ханға булғай даимән алғыш, сәуаб.

Нагәһан бер қол доғасын ул кәрим
Мөстәҗаб иткәй гөмансыз ул хәким.

Ул доға берлә булуб *и*шләр тәмам,
Дә*в*ләт ичрә күб йәшәгәй шаһ мөдам.

Имди *(...)*уш васф*е* халем әйтә*л*ем,
Бер теләгем бар аны йад итә*л*ем:

*Җөн сынадым* ирсә дөнйа эшени,
*55б кәгазь* *Сөйлә*дем аның фетнә вә тәшвишени:

Би вәфа ирмеш бу дөнйа – аңладым.
Әсри күб ирмеш җәфасы – таңладым.

---

[*] Кульязмада ялгыш «йу» дип язылган.
[**] Кульязмада ялгыш «шәна» дип язылган.

Аны таңлаб ултурурда нагәһан
Хатеремғә төшти фикрәт ул зәман.

Кем мөбарәк Урдуға барса*(...)* үзүм
*Хан*ның қотлуғ йөз*не* күрсә күзүм,

Ул дәм ичрә күб доға қылғай и*(...)*дем,
Йар*л*ылықым сүзени айғай и*(...)*дем.

Қылғай ирди йарлықаб мәңа нәзар,
*56а кәгазь* Қәйра булғай ирди эшем мөғтәбәр.

*Бетк*әй ирди теләкем бар*җә* рәуан.
Кем ғинайәт қылса ул шаһи җәһан.

Ни қылайым кем кө*җ*үм йуқдур, дәриғ,
Кем ирүр мөфлислек иргә бәс қәтиғ.

Ханға лаиқ һ*иҗ* нә ирсәм йуқ бүләк,
Урд*а*ға бармақға һәм қ*уүә*т кәрәк.

*Җ*өн бу фикрәт ичрә қалдым бер зәман,
Хәқ тәғалә лотф қылды нагәһан.

Қылды мәңа бу күңүл *шәйех* хитаб,
*56б кәгазь* Кем аның сүзе берлә төз*(...)*дүм китаб.

Хал теле берлә мәңа айға*н* сүзе
Бу ирүр – мәңа әйде ул үзе:

«Кем, әйа, д*а*рвиш мескин дәрднак,
*Ғосса* берлә қылма үз*е*ңни һәлак.

Тасниф иткел төрки теленчә *бер* китаб,
Падишаһ атыға аны хуш йәсаб.

Кем Сөләйман йа*ң*лиғ ирүр хәзрәти,
Мөстәдам булсун җәһанда дәвләти.

Һи*җ* нимәгә ихтийаҗы йуқ торур,
*57а кәгазь* Хезмәтендә бар*җ*әси анук торур.

Дөнйа без буланч*а* күр*е*нмәз күзенә,
Сән қым*у*рысқа йа*ң*лиғ имди үзенә.

Ул китабың үтүн*ү*б *и*згыл рәуан,
Рәх*и*м қылғай *кем* сәңа *(...)* шаһы җәһан.

Рәх*ме* берлә эшең*(...)* булғай тәмам,
Рахәт иткәйсән һәмишә, вәс-сәлам».

Чөн күңүл*(...)* *шәйех* сүзен*е* тыңладым,
Ни ишарәт қылды ирсә – аңладым.

Қәзғудин булды хәлас ул дәм күңүл,
*57б кәгазь* Ғашиқанә сүзүни қылды*м* қәбул.

Алдым *и*лкем*г*ә қәләмни ул зәман,
Телгә ни кем килсә күңүлдин рәуан,

Бетийү башладым ул сағәт қәмуғ,
Ғишық берлә тыңла*гай* *(...)* кечек-олуғ.

Бер хикайәт қылайым сезгә бу дәм,
Нәқеш итә*р* кагәз*(...)* *үзә* аны қәләм[*].

Бер хикайәт қылайым, ғаләм ханы,
Йалған ирмәс, күни, тыңлаңыз аны.

*58а кәгазь* Рауилар*(...)* аны риуайәт қыл*у*р уш,
Сидық берлә ишетеңез бар*җ*ә хуш.

---

[*] Бу урында тәнкыйди текстта булган «Хикайәт» сүзе язылмаган.

Да*вы*д уғлы ул Сөләйман, Хәқ рәсүл,
Бикләрени йиғды бер көн бар*җ*ә ул.

Өндәде ул көн вәзирләрен мәгәр,
Туй булур диб қылды бар*җ*әға хәбәр.

Тигмә *бу* бикләр вә вәзирләр килдиләр,
Ул зәманда бер олуғ туй қ*ы*лдилар.

Ил-улус*(...)* килди қәмуғ*ы* йыйғылыб,
Тигмә бере бер лятиф т*иге*ш алыб.

*58б кәгазь* Төр*лүк* таңсуқ күп т*иге*ш килтүрдиләр
Тигмәси үз қадерен *белдүрделәр.*

Бик, вәзирләр ултурурда ул зәман –
Ул олуғлар арасында нагәһан

Килди бер турғай йырақ*(...)дин* талыб,
Бер сар*ынчақ* б*от*ын ағзыға алыб.

Әйде кем булсун мөбарәк ошбу туй,
Хасил итү белмәдем[*] һ*иҗ йанлыйг,* қуй.

И, Сөләйман, ошбу ирүр табқаным,
Җәһд берлә туйға хасил қылғаным.

*59а кәгазь* Дөнйа*да* ирүр қанәғәт тәк эшем,
Халемә күрә*(...)* ирүр уш т*иге*шем.

Ул нәби Аллаһ Сөләйман, и йегет,
*Җ*өнкә турғай сүзен аңлады, ишет.

Ғөзрени лотф*е* билә қылды қәбул,
Булмады турғай сүзендин һич мәлул.

---

[*] Бу сүз кулъязмада ялгыш «сүлмәдем» дип язылган.

Ул дәм уқ турғайны ул суйурғады,
Йар*л*ы турғай эүгә барыб *и*рғады.

Мән тәқи имди, әйа шаһ*е* җәһан,
Булдым ул турғай мәңизли*к* бу зәман.

*59б кәгазь* Хәзрәте*ң*ә йар*лы*лықым белдүр*е*б,
Уш мона таб*г*ан т*иге*шем килтүрүб,

Хәзрәтеңез *ул* Сөләйман тәк ирер,
Дөнйаның таңсуқлари сездә *торур*.

Уш көчүм йетәр*җ*ә төрки китаб
Нәзым қылдым падишаһ атын атаб.

Лотфыңыздән қылсаңыз аны қәбул,
Хәстә күңлүм булмағай ирди мәлул.

Қылғай ирдем *(...)*җан *барынҗа* мән доға,
Айғай ирдем җан вә дил берлә сә*н*а.

# МӨХӘММӘДЬЯРНЫҢ «НУРЫ СОДУР» ПОЭМАСЫ ТЕРКӘЛГӘН КУЛЪЯЗМАЛАРГА ТАСВИРЛАМА

## «Уразай нөсхәсе»

*(Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1116 т» шифры белән саклана)*

Бу кулъязма җыентык 1701–1710 елларда Һолландиядә эшләнгән, 15,5х19,5 сантиметр зурлыктагы юка саргылт кәгазьдә, текстларының күпчелек өлеше караңгы көрән, ә кайбер урыннары ачык көрән төстәге кара белән язылган. Шулай ук кызыл кара белән язылган урыннары да бар. Кәгазенең эшләнгән вакытына караганда, җыентык XVIII йөзнең беренче чирегендә күчерелгән дип әйтергә була.

Кулъязманың сакланышы уртачадан начаррак: күп кенә битләренең аскы өлешләре тетелгән һәм җуелган. Шактый урыннарда язу карасы юка кәгазьне бозып, тишкәләгән. Төбеннән тегелгән җебе сүтелгән һәм бөтен битләре дә диярлек бер-береннән аерылган.

Җыентыкта бер үк кеше кулы белән берничә текст язылган.

Аның 1а кәгазенең өске, уң як почмагында төрки-татарча дога теркәлгән.

1б–11б кәгазьләрендә мәшһүр суфи Мансур әл-Хәллаҗга багышланган күләмле шигъри әсәр – поэма тексты язылган. Мансур әл-Хәллаҗ (Әбел-Могыйс әл-Хөсәен бине Мансур әл-Бәйзави, 858–922) вәгазь-нәсихәтләрендә Ислам диненең төп өйрәтмәләреннән тайпылганы һәм бигрәк тә «әнә әл-Хакъ» (Мин – Аллаһ) дигән сүзләре өчен Бәгъдадта үлем җәзасына (яндырып үтерелүгә) хөкем ителгән шәхес. Суфилар карашынча, Аллаһ бөеклегенә ирешеп, аның белән кушылу (ягъни, «әнә әл-Хакъ») – суфичылыкның иң югары дәрәҗәсе дип саналган.

Ислам динен тоткан төрле халыкларның авыз иҗатында һәм суфичылык әдәбиятында Мансур әл-Хәллаҗ шәхесенә зур игътибар бирелгән, әдәби әсәрләр иҗат ителгән. Ләкин менә бу кулъязма җыентыктагы поэма тексты төрки-татар әдәбиятында әлегә кадәр билгесез иде. Аның текстының шактый өлеше сакланып калган булса да, ахыры – гадәттә, әсәрне иҗат итүченең исеме язылган өлеше сакланмаган. Шуңа күрә бу поэма авторының кем булганлыгы хәзергә билгесез. Кереш мәкаләбездә әйтеп үтелгәнчә, Мансур әл-Хәллаҗ турындагы әсәрнең шигъри төзелеше һәм текстологик үзенчәлекләре Мөхәммәдьяр поэмаларына шактый аваздаш. Киләчәктә бу текст тирәнтен өйрәнелер һәм башка күчермәләре дә табылса, бәлки, авторлыгы ачыкланыр дип ышанасы килә.

Бу текстның башы (1б кәгазьдә): *Бисмиллаһи рахмани рахим.*

*Әүвәл аны әйдәлем кем, Хәкъдур ул,*
*Хәййе баҡи, вахиде мотлаҡдур ул.*

Ахыры (11б кәгазьдә):

*Диделәр: җаду улмыш ошбу кеши,*
*Дәйү* ................................ *эши.*

Поэма тексты кулъязманың бер битендә 16 юл булып, 9,5х15 см күләмендәге мәйданда язылган.

Кулъязманың сакланыш халәте төгәлрәк күзаллансын өчен, битләп күзәтик:

1 нче кәгазьнең читләре һәм түбәнге өлеше бик тетелгән.

2 нче кәгазе дә ерткаланган, аскы өлеше ертылып җуелган.

3 нче кәгазь – 13х6 см зурлыгындагы фрагменттан гыйбарәт. Кәгазь битенең түбәнгерәк өлешен тәшкил итә.

4–8 нче кәгазьләре ерткаланган һәм читләре тетелгән.

9 нчы кәгазьнең түбәнге өлеше ертылган, язулы 10 юлы гына сакланган.

10 нчы кәгазьнең шулай ук аскы өлеше юк, 12 юлы укыла.

11 нче кәгазьнең дә түбәнге ягы ертылган, 15 юлын укырга мөмкин.

Җыентыкның 12а–28б кәгазьләрендә Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән мәшһүр татар шагыйре Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы язылган. Текстның баш өлеше сакланмаган, төп өлеше һәм ахыры бар. Тексты, алда әйтелгән Мансур әл-Хәллаҗ



*«Нуры содур» поэмасының Уразай нөсхәсе. 22б кәгазь.*

поэмасыныкы кебек үк, бер биттә 16 юл булып, 9,5х15 см мәйданында язылган.

Бу текстның башы (12а кәгазьдә):

*Тигүрәйен мән хәлифәгә аны,*
*Кем эчүб кәүсәр сывын, тынсун җаны.*

Ахыры (11б кәгазьдә):

*Тәмам булды «Нуры содур» китабы,*
*Нәдүр фәқир йазғучының гөнаһы.*

Текстның башы Мөхәммәдьяр әсәрләренең 1997 елгы тәнкыйди басмасындагы 269 нчы бәйткә туры килә, бетем өлеше дә басма китаптагыга тәңгәл.

Кулъязманың «Нуры содур» поэмасы язылган өлешенең битләре шулай ук начар сакланган:

12 нче кәгазе уң яктан тетелеп, өлешчә ертылган.

13–16 нчы кәгазьләренең читләре тузган. Аскы уң як почмагы һәм түбәнге өлеше таушалганлыктан, язулары начар укыла.

17–18 нче кәгазьләр башка битләргә караганда ныграк тузган, сүзләр язылган урыннары тишкәләнгән, түбәнге өлешләре ертылып төшкәнлектән, астагы юллары начар укыла яки бөтенләй сакланмаган. 18 нче кәгазьнең ике ягында да түбәндәге икешәр бәйте җуелган.

19–20 нче кәгазьләрнең түбәнге өлешләре таушалган, шунлыктан астагы юлларны тулаем уку мөмкин түгел.

21 нче кәгазьнең дә асты ертык, ул 15,5х16 см зурлыгында. 21а кәгазьдә – 13,5 юл, ә 21б кәгазьдә 14,5 юлы укыла.

22–23 нче кәгазьләрнең түбәнге өлешләре аеруча таушалган.

24–25 нче кәгазьләрнең читләре һәм аскы өлешләре тетелгән, текст язылган урыннары тишкәләнгән.

26 нчы кәгазьнең асты ертылган (15,5х17 см), тексты тишкәләнгән.

27 нче кәгазьнең аскы өлеше бик тузган.

28 нче кәгазьнең асты һәм сул чите ертык, тексты тишкәләнгән.

«Нуры содур»ның 5–9 нчы баб-бүлек исемнәре (12б, 14б, 16б, 18б һәм 20а кәгазьләрдә), 18б кәгазьдә баб исеме астындагы эпиграф рәвешендәге «Калә Аллаһы Тәгалә...» гыйбарәсе һәм өч урында (15б, 17б һәм 20б кәгазьләрдә) «Хикайәт» сүзе кызыл кара белән язылган.

Поэма ахырындагы бәйтләрнең берсендә (28б кәгазьдә):

*Җөмадел-ахыр айының егермесе*
*Ки булды бу китабның интиһасы,*

– диелгән. Мондагы «җөмадел-ахыр айының егермесе» дигән сүзләр кулъязманы күчергән кешенең бу эшне тәмамлаган вакытын белдерә. Шул ук биттә, колофоннарга хас эчтәлектәге фарсыча ике юл шигырь дә поэма текстының ахырына күчерүче тарафыннан өстәп язылган.

Кулъязма җыентыкның аннан соңгы 28б–33а кәгазьләрендә намаз тәртипләре турындагы дини эчтәлекле төрки-татарча текст язылган. Аның башында кызыл кара белән язылган исеме буялып һәм уңып беткән. Текстының мәйдан күләме 10,5х15 см зурлыгында. Бу текст язылган битләр дә бик таушалып, тишкәләнеп һәм түбәнге өлешләре ертылып төшкән.

Җыентыкның 33а–34б кәгазьләрендә гарәп телендә «Хикайәте дәһри» исемле текст язылган. Аның исеме кызыл кара белән бирелгән. Бу ике бит аеруча тузган хәлдә.

Кулъязмадагы бөтен текстлар да гарәп язуының тәгъликъ төре белән язылганнар. Кайбер хәрефләрне язганда шикәстә язуы элементлары да кулланылган. «Уау» хәрефе өстендә һәм «син» хәрефе астында өчәр нокта куелган очраклар бар. Кайбер сүзләрне язганда хәрәкәләр кулланылган. Ялгыш язгач өстеннән сызып, төзәтеп яки текст читенә чыгарып язылган сүзләр дә бар. Кустодлары тотрыклы язылган.

Китапханәгә бу җыентык, башка кулъязма истәлекләр белән бергә, Гөлназ Гариповадан 1999 елның 11 маенда алынды. Ул аны туган авылы Уразайда (Кукмара районы) яшәүче Имаметдин Ибраһим улы Ибраһимовтан алган. Әлеге кулъязмалар Ибраһимовлар гаиләсенә бабалары – Галиулла улы Ибраһимнан калган.

## «Ижевск нөсхәсе»

*(китапханәдә «2071 т» шифры белән саклана)*

Кулъязма дәфтәрнең битләре саргылт төстәге Россия кәгазеннән гыйбарәт. Филиграньнәреннән күренүенчә, поэма тексты язылган кәгазь 1748–1756 елларда Ярославль шәһәрендәге Алексей Затрапезный мануфактурасында эшләнгән. Дәфтәр ике ягы да язулы, 11х17 см зурлыктагы 59 кәгазьдә. Сакланышы яхшы. Кулъязма җеп белән берничә дәфтәрчеккә бүленеп тегелгән. Язуының карасы – караңгы коңгырт төстә.

Бу дәфтәрдә бары тик «Нуры содур» поэмасы гына язылган. Поэма текстының баш өлеше һәм ахыры сакланмаган. Һәр биттәге текст мәйданы 7х12,5 см тәшкил итә. Дәфтәрнең һәр битендә унар юл. Кәгазенең форматы җыйнак булганга шигъри юллар бер-бер артлы тезеп язылган.

Кулъязманың 8–9, 14–15, 23–24, 53–54 кәгазьләре арасында, берәр кәгазьләре төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән.

Поэманың башы (1а кәгазьдә):

*Бер хәдис мәгнәсен әйтәйен сәхих,*
*Җан вә дил берлә ишеткел уш сәрих.*

Ахыры (59б кәгазьдә):

*Қылғай ирдем җан барынҗа мән доға,*
*Айғай ирдем җан вә дил берлә сәна.*

Башы тәнкыйди басманың 153 нче бәйтенә, ә ахыры 771 нче бәйтенә туры килә.

Кулъязманың язу төре – гади татар тәгъликы. Палеографик үзенчәлекләренә килгәндә, текстның күпчелек урыннарында «ч» хәрефе урынына «җ» язылган. Берничә урында, киресенчә, «җ» урынына «ч» хәрефе (мәсәлән, 643 нче бәйттәге «мөҗиб» сүзе «мөчиб» дип) язылган. «Уау» хәрефе өстендә һәм «син» хәрефе астында өчәр нокта, сүз ахырындагы «йа» хәрефе астында икешәр нокта куелган. Тексттагы кайбер сүзләр хәрәкәләр белән язылган. Шулай ук иске язма текстларга хас булганча, төрки-татар сүзләрендә бер төрле үк хәреф янәшәдә ике мәртәбә килгәндә, хәреф бер генә тапкыр язылган. Мәсәлән, «итте» сүзе «ите» рәвешендә бирелгән. Кустодлары бар.

Китапханәгә бу юлларның авторыннан алынды.

# РЕЗЮМЕ

Четвертая книга серии «Татарская археография» представляет собой публикацию двух вариантов текста поэмы «Нур-и судур» (Свет сердец) татарского поэта XVI века Мухаммедьяра, написанной в 1541 году.

Рукописи поэмы известны в настоящее время в одиннадцати списках, которые хранятся в научных библиотеках Казани, Петербурга, Уфы, а также в личных архивах учёных.

Публикуемые в данном сборнике два списка хранятся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Первый из них был передан библиотеке в мае 1999 года студенткой Татарского государственного гуманитарного института Г.Гариповой, который она приобрела у жителя деревни Уразаево Кукморского района Республики Татарстан И.Ибрагимова. Вторая рукопись поэмы была приобретена автором этих строк летом 2004 года в городе Ижевске у Р.Давлетшиной. Филиграни на бумаге первого списка свидетельствуют, что данная бумага была изготовлена в Голландии в 1701–1710 годах. А филиграни бумаги ижевского списка означают, что она является продукцией мануфактуры Алексея Затрапезного из г. Ярославля 1748–1756 годов. Об этих ценных археографических находках впервые нами было сообщено в статьях, опубликованных в журналах «Библиотечный вестник» (2001. – № 1) и «Казан утлары» (2002. – № 3; 2005. – № 7).

Среди всех известных одиннадцати списков поэмы «Нур-и судур» по полноте текста ижевская рукопись занимает пятое (1165 стихотворных строк), а уразаевская – восьмое место (1023 строк). В рукописях имеется немало текстологических особенностей, отличающих их от изданного в 1997 году критического текста поэмы, подготовленного учёным Ш.Абиловым. Особенно ценны имеющиеся в рукописях ранее неизвестные четыре двустишия, а также краткие изречения из Корана и текст хадиса, представленные в виде эпиграфов в некоторых главах поэмы. Последние, нужно полагать, не являются вольными дополнениями переписчиков, а существовали в авторском варианте поэмы «Нур-и судур». Благодаря

этим спискам были установлены правильные варианты некоторых слов, в отношении которых ранее допускалось разночтение.

Тексты обоих списков в сборнике публикуются полностью, в них указаны все текстологические особенности, отличающие их от критического текста поэмы, изданного в 1997 году.

В данном сборнике, кроме текстов поэмы Мухаммедьяра, помещена статья, посвященная публикуемым источникам, а также археографическое описание текстов рукописей. Текст произведения представлен в транслитерации современной татарской графики.

Во вступительной статье упоминается о том, что в рукописном сборнике из деревни Уразаево была обнаружена важная археографическая находка – текст другого, не менее интересного по содержанию, произведения. Эта поэма посвящена известному в мусульманской истории Мансуру аль-Халладжу (858–922), казнённому за свои суфийские взгляды. Легенда о нём стала привлекательной темой множества художественных произведений разных народов исламского мира. Однако поэтический текст, неполностью сохранившийся в вышесказанном сборнике, ранее не был известен татарским литературоведам. Она интересна тем, что стиль и языковые особенности очень близки к поэмам Мухаммедьяра. Хотя говорить об авторстве этой поэмы ещё рано, но с уверенностью можно предположить, что она была написана не позднее XVI века.

ЭЧТӘЛЕК

*Мәрданов Р.* «Бу китап хан догасы берлә тәмам...» ............................ 3

ПОЭМА ТЕКСТЛАРЫНЫҢ
ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ЯЗУЫНА
КҮЧЕРЕЛМӘСЕ

УРАЗАЙ НӨСХӘСЕ ........................................................................ 16
ИЖЕВСК НӨСХӘСЕ ........................................................................ 64

*Мәрданов Р.* Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасы
теркәлгән кулъязмаларга тасвирлама .............................................. 119

Резюме ........................................................................................... 125

Мухаммедьяр

**НУР-И СУДУР**

*(на татарском языке)*

поэма

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 25. 05. 2009. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ № 256.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 25. 05. 2009. Формат 60x84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ № 256.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники
редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.